МИНИСТЕРСТВО ПО ДЕЛАМ
ГРАЖДАНСКОЙ ОБОРОНЫ
И ЧРЕЗВЫЧАЙНЫМ СИТУАЦИЯМ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ГРАЖДАННАР ОБОРОНАСЫ
ЭШЛӘРЕҺӘМ ГАДӘТТӘН ТЫШ
ХӘЛЛӘР МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** г. Казань **БОЕРЫК**

20.07.2016 № 310

Татарстан Республикасы гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы белән халыкны һәм территорияләрне региональ, муниципальара һәм муниципаль үзенчәлектәге гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә дәүләт региональ күзәтүне тормышка ашыру буенча дәүләт функцияне башкару буенча Административ регламентны раслау турында

“Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары белән дәүләт функцияләрен башкару буенча административ регламентларны эшкәртү һәм раслау тәртибен раслау турында” 2012 ел 31 нче декабрь № 1192 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына туры китереп һәм 2004 ел 30 нчы декабрь № 614 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Карары белән расланган Татарстан Республикасы гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы турында Кагыйдәнамәнең 3.1 пунктына туры китереп, б о е р ы к б и р ә м:

1. Кушылган Татарстан Республикасы гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы белән халыкны һәм территорияләрне региональ, муниципальара һәм муниципаль үзенчәлектәге гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә дәүләт региональ күзәтүне тормышка ашыру буенча дәүләт функцияне башкару буенча Административ регламентны (алга таба – Регламент) расларга.

2. Министрлыкның хокук тәэминаты бүлеге башлыгы С.В. Халиловка Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында биредәге боерыкны дәүләт теркәү һәм киләчәктә аны Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының хокук мәгълүматы рәсми сайтына (PRAVO.TATARSTAN.RU) рус һәм татар телләрендә урнаштыру эшен оештырырга.

3. Министр эшләрен идарә итүчесе А.В. Молевка Административ регламентны Татарстан Республикасы Хөкүмәте рәсми порталының Татарстан Республикасы ГТХМ субпорталында урнаштыруны тәэмин итәргә.

4. Биредәге боерыкны вазифалы шәхесләргә тарату исемлегенә туры китереп җиткерергә.

5. Биредәге боерыкны башкару артыннан контрольне министр урынбасары Н.В. Суржкога йөкләргә.

Министр Р.Җ. Хәбибуллин

А.С. Зайцев
221-62-33

2016 ел 20 нче июль № 310
Татарстан Республикасы ГТХМ
боерыгы белән расланган

Татарстан Республикасы гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы белән халыкны һәм территорияләрне региональ, муниципальара һәм муниципаль үзенчәлектәге гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә дәүләт региональ күзәтүне тормышка ашыру буенча дәүләт функцияне башкару буенча
Административ регламент

## I. Гомуми кагыйдәләр

### Дәүләт функциясенең исеме

1. Биредәге Регламент халыкны һәм территорияләрне региональ, муниципальара һәм муниципаль үзенчәлектәге гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә дәүләт региональ күзәтүне тормышка ашыру буенча дәүләт функциясен (алга таба – дәүләт функциясе) башкару буенча Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгының административ процедураларының (гамәлләренең) срокларын һәм элеклелеген билгели.

### Дәүләт функциясен башкара торган Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органының исеме

2. Дәүләт функциясен башкаруы Татарстан Республикасы гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы (алга – таба күзәтү органы) белән тормышка ашырыла.

Туры килә торган мәгълүматны бердәм тикшерүләр реестрына кертү “Дәүләт контрольне (күзәтүне) һәм муниципаль күзәтүне тормышка ашырганда юридик шәхесләрнең һәм индивидуаль эшмәкәрләрнең хокукларын яклау турында” 2008 ел 26 нчы декабрь № 294-ФЗ Федераль законының 13.3 статьясына һәм “Бердәм тикшерүләр реестрын формалаштыру һәм алып бару кагыйдәләре турында” 2016 ел 28 нче апрель № 415 Русия Федерациясе Хөкүмәте карарына (алга таба – № 415 РФ Хөкүмәте карары) туры китереп күзәтү органының вәкаләтле вазифалы шәхесе белән тормышка ашырыла.

Дәүләт функциясен башкаруны тәртипкә сала торган норматив хокук актлары исемлеге

3. Дәүләт функциясен башкаруы түбәндәге Русия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнар чыгара торган һәм башка норматив хокук актларына туры китереп тормышка ашырыла:

Русия Федерациясе Гражданлык кодексы (Российская газета, 1994, 8 нче декабрь, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

2001 ел 30 нчы декабрь № 195 Федераль законы (Собрание законодательства Российской Федерации, 2002, № 1, ст. 1, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган Административ җинаятьләр турында Русия Федерациясе кодексы;

2002 ел 24 нче июль № 95-ФЗ Федераль законы белән расланган Русия Федерациясе арбитраж процессуаль кодексы (Собрание законодательства РФ, 2002, № 30, ст. 3012, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

“Дәүләт сере турында” 1993 ел 21 нче июль № 5485-1 Русия Федерациясе законы (Собрание законодательства РФ, 1997, № 41, 8220-8235 битләр, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып)

“Русия Федерациясе гражданнарының мөрәҗәгатьләрен карап тикшерү тәртибе турында” 2006 ел 2 нче май № 59-ФЗ Федераль законы (Собрание законодательства РФ, 2006, № 19, ст. 2060, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

“Дәүләт контролен (күзәтүен) һәм муниципаль контролен тормышка ашырганда юридик шәхесләрнең һәм индивидуаль эшмәкәрләрнең хокукларын яклау турында” 2008 ел 26 нчы декабрь № 294-ФЗ Федераль законы (Собрание законодательства РФ, 2008, № 52, ст. 6249, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

“Халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген үзенчәлектәге гадәттән тыш хәлләрдән саклау турында” 1994 ел 21 нче декабрь № 68-ФЗ Федераль законы (Собрание законодательства РФ, 1994, № 35, ст. 3648, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

“Русия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыру буенча гомуми принциплар турында” 2003 ел 6 нчы октябрь № 131-ФЗ Федераль законы (Собрание законодательства РФ, 06.10.2003, № 40, ст. 3822, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

“Русия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгара торган (сайланган) һәм башкаручы органнарының оештыруы буенча гомуми принциплар турында” 1999 ел 6 нчы октябрь №184-ФЗ Федераль законы (Собрание законодательства РФ, 1999, № 42, ст. 5005, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

“Куркыныч объектта авария нәтиҗәсе буларак зыян китерү өчен куркыныч объект хуҗасының гражданлык җаваплылыгын мәҗбүри страховкалау турында” 2010 ел 27 нче июль № 225-ФЗ Федераль законы (Собрание законодательства РФ, 2010, № 31, ст. 4194, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

“Радиацион иминлек турында” 1996 ел 9 нчы гыйнвар №3-ФЗ Русия Федерациясе Федераль законы (Собрание законодательства Российской Федерации, 1996, № 3, ст. 141, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

“Хәвефле җитештерү объектларның сәнәгый иминлеге турында” 1997 ел 21 нче июль № 116-ФЗ Русия Федерациясе Федераль законы (Собрание законодательства Российской Федерации, 1997, № 30, ст. 3588, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

“Гидротехник корылмаларның иминлеге турында” 1997 ел 21 нче июль Русия Федерациясе Федераль законы (Собрание законодательства Российской Федерации, 1997, № 30, ст. 3589, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

“Гражданнар оборонасы турында” 1998 ел 12 нче февраль № 28-ФЗ Русия Федерациясе Федераль законы (Собрание законодательства Российской Федерации, 1998, № 7, ст. 799, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

“Элемтә турында” 2003 ел 7 нче июль № 126-ФЗ Русия Федерациясе Федераль законы (Собрание законодательства Российской Федерации, 2003, № 28, ст. 2895, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

“Авария-коткару хезмәтләре һәм коткаручылар статусы турында” 1995 ел 22 нче август № 151-ФЗ Федераль законы (Собрание законодательства РФ, 1995, № 35, ст. 3503, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

“Гадәттән тыш хәлләр килеп чыгу янауы яисә килеп чыгу турында халыкны ашыгыч комплекс белдерү системасын кору турында” (Собрание законодательства РФ, 2012, № 47, ст. 6454);

“Халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген үзенчәлектәге гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә дәүләт күзәтүе турында” 2015 ел 24 нче декабрь № 1418 Русия Федерациясе Хөкүмәте карары (Собрание законодательства РФ, 2016, № 1, ст. 232);

“Гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча бердәм дәүләт системасы турында” 2003 ел 30 нчы декабрь № 794 Русия Федерациясе Хөкүмәте карары (Собрание законодательства РФ, 2004, № 2, ст. 121, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

“Дәүләт контроле (күзәтүе) органнары һәм муниципаль контроль органнары белән юридик шәхесләрне һәм индивидуаль эшмәкәрләрне планлы тикшерүләрне үткәрү буенча ел саен тикшерү планнарның контролен оештыру кагыйдәләрен раслау турында” 2010 ел 30 нчы июнь Русия Федерациясе Хөкүмәте карары (Собрание законодательства РФ, 2010, № 28, ст. 3706, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

“Бердәм тикшерүләр реестрын формалаштыру һәм алып бару кагыйдәләре турында” 2015 ел 28 нче апрель № 415 Русия Федерациясе Хөкүмәте карары (Собрание законодательства РФ, 2015, № 19, ст. 2825);

“Русия Федерациясе территориясендә авария нәтиҗәсе буларак нефть һәм нефть продуктлары түгелүен кисәтү һәм бетерү буенча чараларны оештыру тәртибе турында” 2002 ел 15 нче апрель Русия Федерациясе Хөкүмәте карары (Собрание законодательства РФ, 2002, № 16, ст. 1569, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

“Русия Федерациясе территориясендә авария нәтиҗәсе буларак нефть һәм нефть продуктлары түгелүен кисәтү һәм бетерү буенча кичектергесез чаралар турында” 2000 ел 21 нче август № 613 Русия Федерациясе Хөкүмәте карары

(Собрание законодательства РФ, 2000, № 35, ст. 3582, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

"Табигый һәм техноген үзенчәлектәге гадәттән тыш хәлләр классификациясе турында" 2007 ел 21 нче май Русия Федерациясе Хөкүмәте карары (Собрание законодательства РФ, 2007, № 22, ст. 2640, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

"Русия Федерациясендә табигый һәм техноген үзенчәлектәге гадәттән тыш хәлләрдән халыкны һәм территорияләрне саклау өлкәсендә мәгълүматны җыю һәм алышу тәртибе турында" 1997 ел 24 март № 334 Русия Федерациясе Хөкүмәте карары (Собрание законодательства РФ, 1997, № 13, ст. 1545, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

"Табигый һәм техноген үзенчәлектәге гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә халыкны хәзерләү турында" 2003 ел 4 нче сентябрь № 547 Русия Федерациясе Хөкүмәте карары (Собрание законодательства РФ, 2003, № 37, ст. 3585, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

"Гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча бердәм дәүләт системасының көчләре һәм чаралары турында" 2013 ел 8 нче ноябрь Русия Федерациясе Хөкүмәте карары (Собрание законодательства РФ, 2013, № 46, ст. 5949, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

"Авария-коткару хезмәтләрен, авария-коткару формированиеләрен, каоткаручыларны һәм коткаручы статусын ала торган гражданнарны аттестацияләү буенча кайбер мәсьәләләр турында" 2011 ел 22 нче декабрь № 1091 Русия Федерациясе Хөкүмәте карары (Собрание законодательства РФ, 2012, № 2, ст. 280, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

"Табигый һәм техноген үзенчәлекле гадәттән тыш хәлләрне бетерер өчен материаль ресурс резервларын кору һәм куллану тәртибе турында" 1996 10 нчы ноябрь № 1340 Русия Федерациясе Хөкүмәте карары (Собрание законодательства РФ, 1996, № 47, ст. 5334);

"Дәүләт контролен (күзәтүен) тормышка ашырыр өчен вәкаләт бирелгән органнар, муниципаль контроль органнары белән контроль буенча чараларны үткәрүгә чакырыла торган экспертларны аттестацияләү турында" 2014 ел 10 июль № 636 Русия Федерациясе Хөкүмәте карары (Собрание законодательства РФ, 2014, № 29, ст. 4142);

"Гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча бердәм дәүләт системасы чикләрендә информацион алышу системасы һәм тәртибе турында кагыйдәнамәне раслау турында" 2009 ел 26 нчы август № 496 Русия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм бәла-казаларның нәтиҗәләрен бетерү министрлыгы боерыгы (Российская газета, 2009, 23 нче октябрь);

"Гражданнар оборонасы өлкәсендә халыкны хәзерләү, гадәттән тыш хәлләрдән саклау, янгын куркынычсызлыгын һәм җәмәгать тәртибен саклауны тәэмин итү, шулай да гадәттән тыш хәлләр һәм террористик акцияләре янауы турында гражданнарны вакытында хәбәр итү һәм оператив белдерү максаты белән күп кешеләр була торган урыннарда массакүләм мәгълүматның заманча техник чараларны урнаштыру тәртибе турында" 2005 ел 31 нче май № 428/432/321 Русия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм бәла-казаларның нәтиҗәләрен бетерү министрлыгы, Русия

Федерациясе Эчке эшләр министрлыгы, Русия Федерациясе Федераль иминлек хезмәте боерыгы (Российская газета, 2005, 24 нче июнь, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

“Халыкны белдерү системалары турында кагыйдәнамәне раслау тырында” 2006 ел 25 нче июль № 422/90/376 Русия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм бәла-казаларның нәтиҗәләрен бетерү министрлыгы, Русия Федерациясе Мәгълүмат һәм элемтә министрлыгы, Русия Федерациясе мәдәният һәм массакүләм багланыш министрлыгы боерыгы (Бюллетень нормативных актов федеральных органов исполнительной власти, 2006, № 38);

“Халыкны белдерү системаларында эксплуатацион-техник эшләүне оештыру буенча кагыйдәнамәне раслау турында” 2005 ел 7 нче декабрь № 877/138/597 Русия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм бәла-казаларның нәтиҗәләрен бетерү министрлыгы, Русия Федерациясе Мәгълүмат һәм элемтә министрлыгы, Русия Федерациясе мәдәният һәм массакүләм багланыш министрлыгы боерыгы («Бюллетень нормативных актов федеральных органов исполнительной власти», 2006, № 8);

“Гражданнар оборонасы буенча өйрәнүләрне һәм күнегүләрне хәзерләү һәм үткәрү, халыкны гадәттән тыш хәлләрдән саклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләрнең иминлеген тәэмин итү буенча инструкцияләрне раслау турында” 2013 ел 24 нче апрель № 284 Русия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм бәла-казаларның нәтиҗәләрен бетерү министрлыгы боерыгы (Российская газета, 2013, 2 нче август);

“Русия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм бәла-казаларның нәтиҗәләрен бетерү министрлыгының белем бирү учреждениеләрендә, федераль башкару хакимияте органнарының һәм оешмаларның өстәмә профессиональ белем бирү учреждениеләрендә, Русия Федерациясе субъектларының гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр буенча уку-методика үзәкләрендә һәм муниципаль берәмлекләренең гражданнар оборонасы курсларында яңадан укытуны яисә квалификацияне күтәрүне үтә торган вазифалы шәхесләрнең һәм гражданнар оборонасы эшчеләренең исемлеген раслау турында” 2006 ел 13 нче ноябрь № 646 Русия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм бәла-казаларның нәтиҗәләрен бетерү министрлыгы боерыгы («Гражданская защита», № 2, 2007 (Исемлек);

“Русия Федерациясе субъектларының һәм муниципаль берәмлекләрнең типовой иминлек паспортын раслау турында” 2004 ел 25 нче октябрь № 484 РФ ГТХМ боерыгы (Российская газета, 2014, 29 нчы декабрь, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

“Хәвеф объектның типовой паспортны раслау турында” 2004 ел 4 нче ноябрь № 506 Русия ГТХМ боерыгы (Российская газета, 2005, 19 нчы гыйнвар);

“Индивидуаль саклану чараларны, радиация, химия разведкасы һәм контроле әсбапларын куллану һәм тоту кагыйдәләрен раслау һәм куллануга кертү турында” 2003 ел 27 нче май № 285 Русия ГТХМ боерыгы (Российская газета, 2003, 8 нче август, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

“Халыкны индивидуаль саклану чаралары белән тәэмин итүне оештыру турында кагыйдәнамәне раслау турында” 2014 ел 1 нче октябрь № 543 Русия ГТХМ боерыгы (Бюллетень нормативных актов федеральных органов исполнительной власти, 2015, № 29);

“Штатта булмаган авария-коткару формированиеләрен кору тәртибен раслау турында” 2005 ел 23 нче декабрь № 999 Русия ГТХМ боерыгы. Юстиция министрлыгы белән 2006 ел 19 нчы гыйнварда № 7383 теркәлгән (Бюллетень нормативных актов федеральных органов исполнительной власти, 2015, № 29, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

“Халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген үченчәлектәге гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә федераль дәүләт күзәтүне тормышка ашыру буенча дәүләт функциясен башкару буенча Русия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Административ регламентын раслау турында” 2016 ел 14 нче июнь № 323 Русия ГТХМ боерыгы (Хокук мәгълүматының рәсми интернет-порталы, 2016, 13 нче июль);

“Русия Федерациясе территориясендә нефть һәм нефть продуктлары түгелүен кисәтү һәм бетерү буенча планнарны эшкәртү һәм ризалау кагыйдәләрен раслау турында” 2004 ел 28 нче декабрь № 621 Русия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм бәла-казаларның нәтиҗәләрен бетерү министрлыгы боерыгы (Российская газета, № 95, 2005, 6 нчы май, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

“Русия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм бәла-казаларның нәтиҗәләрен бетерү министрлыгының белем бирү учреждениеләрендә, федераль башкару хакимияте органнарының һәм оешмаларның өстәмә профессиональ белем бирү учреждениеләрендә, Русия Федерациясе субъектларының гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр буенча уку-методика үзәкләрендә һәм муниципаль берәмлекләренең гражданнар оборонасы курсларында яңадан укытуны яисә квалификацияне күтәрүне үтә торган вәкаләтле эшчеләрнең исемлеген раслау турында” 2004 ел 19 нче гыйнвар № 19 Русия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм бәла-казаларның нәтиҗәләрен бетерү министрлыгы боерыгы (Российская газета, № 46, 2004, 6 нчы март);

“Авария түгелүен гадәттән тыш хәлләргә илтер өчен нефть һәм нефть продуктларының түбән дәрәҗә түгелүен билгеләү буенча күрсәтмәләрне раслау турында” 2003 ел 3 нче март № 156 РФ Табигый байлыклар министрлыгы боерыгы (Российская газета, № 93, 2003, 17 нче май);

“Дәүләт контролен (күзәтүен) һәм муниципаль контролен тормышка ашырганда юридик шәхесләрнең һәм индивидуаль эшмәкәрләрнең хокукларын яклау турында” Федераль законының кагыйдәләрен реальләштерү турында” 2009 ел 30 нчы апрель № 141 Русия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгы боерыгы (Российская газета, 2009, 14 нче май, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

“Дәүләт контролен (күзәтүен), җирле үзидарә органнарның һәм җирле үзидарә вазифалы шәхесләренең эшен тикшерүләрен тормышка ашырыр өчен вәкаләт бирелгән дәүләт органнары белән прокуратура органнарында еллык планын формалаштыру һәм ризалау тәртибе турында һәм прокуратура

органнарында җирле үзидарә органнарның һәм җирле үзидарә вазифалы шәхесләренең эшен планнан тыш тикшерүләрне ризалау тәртибе турында” 2014 ел 21 нче апрель № 222 Русия Федерациясе Генераль прокуратурасы боерыгы («Законность», № 7, 2014);

“Халыкны гадәттән тыш хәлләрдә саклау турында” 2004 ел 8 нче декабрь № 62-ЗРТ Татарстан Республикасы законы (Республика Татарстан, 2004, 11 нче декабрь, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

“Халыкны һәм территорияләрне региональ, муниципальара һәм муниципаль үзенчәлектәге гадәттән тыш хәллардән саклау өлкәсендә дәүләт региональ күзәтүне оештыру һәм тормышка ашыру тәртибен раслау турында” 2016 ел 26 февраль № 119 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары («Сборник постановлений и распоряжений Кабинета Министров Республики Татарстан и нормативных актов республиканских органов исполнительной власти» журналы, 2016, № 18-19, ст. 0643);

“Татарстан Республикасы гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгының мәсьәләләре” 2004 ел 30 нчы декабрь № 614 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары («Сборник постановлений и распоряжений Кабинета Министров Республики Татарстан и нормативных актов республиканских органов исполнительной власти» журналы, 2005, № 7, ст. 0206, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

“Татарстан Республикасы гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү территориаль система асты турында” 2004 ел 10 нчы ноябрь № 480 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары («Сборник постановлений и распоряжений Кабинета Министров Республики Татарстан и нормативных актов республиканских органов исполнительной власти» журналы, 2004, № 42-43, ст. 0821, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

“Хәвеф объектларга, халык тормышын тәэмин итүче системалар объектларына һәм күп кеше була торган объектларга Татарстан Республикасы документларының территориаль страховой фондын үстерү турында” 2006 ел 17 нче апрель № 173 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары («Сборник постановлений и распоряжений Кабинета Министров Республики Татарстан и нормативных актов республиканских органов исполнительной власти» журналы, 2006, № 17, ст. 0422, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

“Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары белән дәүләт функцияләрен башкару буенча административ регламентларны эшкәртү һәм раслау тәртибен раслау турында” 2012 ел 31 нче декабрь № 1192 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары («Сборник постановлений и распоряжений Кабинета Министров Республики Татарстан и нормативных актов республиканских органов исполнительной власти» журналы, 25.01.2013, N 7, ст. 0194, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып).

### Региональ дәүләт күзәтү фәне

4. Халыкны һәм территорияләрне региональ, муниципальара һәм муниципаль үзенчәлектәге гадәттән тыш хәллардән саклау өлкәсендә региональ дәүләт күзәтүнең (алга таба – региональ дәүләт күзәтү) фәне җирле үзидарә органнары, юридик шәхесләр, аларның җитәкчеләре, башка вазифалы

шәхесләре, индивидуаль эшмәкәрләре, аларның вазифалы вәкилләре (алга таба – күзәтү объектлары) тарафына халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген үзенчәлектәге гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә Русия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы норматив хокук актлары белән билгеләп куелган таләпләрне үтәүне тикшерү булып тора.

Дәүләт функциясен башкарганда вазифалы шәхесләрнең хокуклары һәм бурычлары

5. Дәүләт функциясен башкарганда күзәтү органының вазифалы шәхесләре хаклы:

хезмәт таныклыгын һәм билгеләп куелган тәртиптә тикшерүне билгеләү турында министрның (министр урынбасарының) расланган әмер копиясен күрсәтеп, күзәтү объектлары эшен тормышка ашырганда кулланылган һәм алар ягына тикшерү үткәрелә торган территорияләр, биналар, корылмалар, төзелешләр һәм бүлмәләргә киртәсез керергә;

халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген үзенчәлектәге гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә күзәтү объектлары таләпләрне үтәгәне тикшерүен башкарырга;

Русия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән исемлеккә кертелгән документларны һәм (яисә) мәгълүматны аларда шул документлар һәм (яисә) мәгълүмат булган башка дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан я дәүләт органнары яисә җирле үзидарә органнарының карамагындагы булган оешмалардан идарәара информацион үзара эш итү чикләрендә Русия Федерациясе Хөкүмәте билгеләп куйган вакыт эчендә һәм тәртиптә түләүсез нигездә, шул исәптән электрон формада, сорарга һәм алырга;

әгәр билгеләнгән документлар һәм мәгълүмат тикшерү фәне белән бәйле булса, күзәтү объекты мәҗбүри таләпләрне үтәгәне буенча тикшерүне оештырыр һәм үткәрер өчен кирәк булган документларны һәм мәгълүматны күзәтү объектларыннан сорарга;

халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген үзенчәлектәге гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә мәҗбүри таләпләрне үтәмәү ягыннан бозуларны бетерү буенча башкарырга мәҗбүри булган кушуларны күзәтү объектларына бирергә;

административ җинаятьләр турында Русия Федерациясе Кодексы һәм Татарстан Республикасы норматив хокук актлары белән билгеләгән тәртиптә административ җинаятьләр турында протоколлар төзергә.

6. Дәүләт функциясен башкарганда күзәтү органының вазифалы шәхесләре бурычлы:

халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген үзенчәлектәге гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә мәҗбүри таләпләр бозуларын кисәтү, эзләп табу һәм туктату буенча аларга Русия Федерациясе законнарына туры китереп бирелгән вәкаләтне вакытында һәм тулысынча башкарырга;

Русия Федерациясе законнарын, тикшерелә торган күзәтү объектларының хокукларын һәм законлы кызыксынуларын үтәргә;

Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрының (алга таба – министр), Татарстан Республикасы

Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министры урынбасарының (алга таба – министр урынбасары) билгеләп куелганча тикшерүне үткәрү турында әмере нигезендә тикшерүне үткәрергә;

тикшерүне хезмәт бурычларын башкарган вакытта гына, күчмә тикшерүне хезмәт таныклыкларын, министр, министр урынбасары әмере копиясен һәм № 294-ФЗ Федераль законының 10 нчы статьясы, 5 нче бүлеге белән билгеләнгән очракта тикшерүне үткәрү ризалауы турында документ копиясен күрсәткәндә генә үткәрергә;

күзәтү объектының җитәкчесенә, башка вазифалы шәхесенә яисә вәкаләтле вәкиленә тикшерүне үткәргәндә булырга, тикшерү фәне белән бәйле сорауларга аңлатмалар бирергә каршы килмәскә;

тикшерүне уздырганда булган күзәтү объектының җитәкчесенә, башка вазифалы шәхесенә яисә вәкаләтле вәкиленә тикшерү фәненә кагылган мәгълүматны һәм документларны күрсәтергә;

күзәтү объектының җитәкчесен, башка вазифалы шәхесен яисә вәкаләтле вәкилен тикшерүнең нәтиҗәләре белән таныштырырга;

күзәтү объектының җитәкчесен, башка вазифалы шәхесен яисә вәкаләтле вәкилен идарәара информацион үзара эш итү чикләрендә алынган документлар һәм (яисә) мәгълүмат белән таныштырырга;

эзләп табылган бозу фактлары буенча кабул ителә торган чараларны билгеләгәндә билгеләнгән чаралар бозу авырлыгына, кешеләрнең гомеренә, сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирә мохитка, Русия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарих һәм мәдәният памятникларына), дәүләт иминлегенә, табигый һәм техноген үзенчәлекле гадәттән тыш хәлләр килеп чыгу потенциаль янауларына туры килгәнен исәпкә алырга, шулай да күзәтү объектының хокукларын һәм законлы кызыксынуларын нигезсез рәвештә булдырмаска;

Русия Федерациясе законнары белән билгеләп куелган тәртиптә риза булмыйча шикаять биргәндә үз гамәлләренең төпле булуын дәлилләргә;

№ 294-ФЗ Федераль законы белән билгеләп куелган тикшерүне үздыру срокларын үтәргә;

Русия Федерациясе законнары белән алдан билгеләнмәгән документлар һәм башка мәгълүматлар күрсәтүне күзәтү объектларыннан таләп итмәскә;

күчмә тикшерүне үткәрер алдыннан күзәтү объекты үтенече буенча аны туры китереп үткәрелә торган биредәге Регламентның кагыйдәләре белән таныштырырга;

2018 елның 31 нче декабренә кадәр планлы тикшерүне үткәргән вакытта күзәтү объектының җитәкчесенә, башка вазифалы шәхесенә яисә вәкаләтле вәкиленә планлы тикшерүне үткәрү тукталганы турында аңлатырга, моның турында туры килгән акт төзелә, планлы тикшерү үткәрелә торган юридик шәхесне, индивидуаль эшмәкәрне Русия Федерациясе законнары белән билгеләнгән кече эшмәкәрлек субъектларына кителелгәнне раслый торган документларны күзәтү органының вазифалы шәхесләренә биргән һәм № 294-ФЗ Федераль законының статья 26.1 нең 2 нче бүлегендә алдан исәпләнгән мәгълүмат булмаган очракта;

тикшерүләр исәбе журналында (ул юридик шәхестә һәм индивидуаль эшмәкәрдә булган очракта) үткәрелгән тикшерү турында язу башкарырга.

Тикшерүне үткәргәндә күзәтү органының шәхесләре хаксыз:

халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген үзенчәлектәге гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә мәҗбүри таләпләрне башкаруны тикшерергә, әгәр шул таләпләр күзәтү органының исеменнән эшли торган шул вазифалы шәхесләрнең вәкаләте белән бәйле булмаса;

планлы яисә планнан тыш күчмә тикшерүне үткәргәндә күзәтү объектының җитәкчесе, башка вазифалы шәхесе яисә вәкаләтле вәкиле булмаган очракта тикшерүне тормышка ашырырга, кешеләрнең гомеренә, сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирә мохитка, Русия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарих һәм мәдәният памятникларына), дәүләт иминлегенә зыян китерү, шулай да табигый һәм техноген үзенчәлекле гадәттән тыш хәлләр килеп чыгу сәбәпләре буенча шундый тикшерүне үткәрү очрагыннан тыш;

күзәтү объектлары тикшерүнең объектлары булып тормаса яисә тикшерү фәне белән бәйле булмаса, күзәтү объектыннан документларны, мәгълүматны китерергә таләп итәргә, шулай да шундый документларның оригиналларын тартып алырга;

тикшерүне үткәрү нәтиҗәсе буларак алынган һәм дәүләт, коммерция, хезмәт, закон белән башка саклана торган серле мәгълүматны таратырга, Русия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары белән алдан исәпләнгән очраклардан тыш;

тикшерүне үткәрүнең билгеләп куелган срокларыннан читкә чыгу;

күзәтү объектларына аларның исәбенә контроль буенча чараларны үткәрү турында кушуларны һәм тәкъдимнәрне бирүне тормышка ашырырга;

СССР һәм РСФСР башкарма хакимияте органнарының норматив хокук актлары белән билгеләп куелган һәм Русия Федерациясе законнарына туры килми торган таләпләрне башкаруны тикшерергә;

продукция үрнәкләрен, әйләнә-тирә мохит объектларын һәм җитештерү мохит объектларын тикшереп карау пробаларын аларның тикшерүләрен, сынауларын, үлчәүләрен үткәрер өчен билгеләнгән үрнәкләрне, пробаларны алу турында билгеләп куелган формада протоколларны рәсмиләштермичә милли стандартлар, үрнәкләрне, пробаларны алу кагыйдәләре һәм аларның тикшерү, сынау, үлчәү методлары, техник регламентлары яисә алар көченә кергән көненә кадәр гамәлдә булган башка норматив техник документлар һәм тикшерү, сынау, үлчәү кагыйдәләре һәм методлары белән билгеләп куелган нормалардан артык күләмдә алырга;

халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген үзенчәлектәге гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә мәҗбүри таләпләрне һәм Русия Федерациясе законнары белән билгеләп куелган тәртиптә матбугатка чыгарылмаган муниципаль хокук актлары белән билгеләп куелган таләпләрне башкаруны тикшерергә;

юридик шәхестән, индивидуаль эшмәкәрдән документларны һәм (яисә) мәгълүматны китерергә таләп итәргә, шул исәптән башка дәүләт органнарының, җирле үзидарә органнарының, я дәүләт органнарының яисә җирле үзидарә органнарының карамагындагы Русия Федерациясе Хөкүмәте

белән билгеләнгән исемлеккә кертелгән оешмаларның файдалануында булган рөхсәт итү документларны (биредәге абзацның таләбе 2017 елның 1 гыйнварыннан гамәлдә);

юридик шәхестән, индивидуаль эшмәкәрдән Русия Федерациясе законнарының таләпләренә туры китереп элек китерелгән һәм (яисә) дәүләт яисә муниципаль информацион системаларда, реестрларда һәм регистрларда булган мәгълүматны китерергә таләп итәргә (биредәге абзацның таләбе 2017 елның 1 гыйнварыннан гамәлдә).

Шәхесләргә күзәтү буенча чаралар үткәрелә торган шәхесләрнең хокуклары һәм бурычлары

7. Тикшерү үткәрелгәндә күзәтү объектының җитәкчесе, башка вазифалы шәхесе яисә вәкаләтле вәкиле хаклы:

тикшерү үткәрелгәндә турыдан-туры булырга, тикшерү фәне белән бәйле сораулар буенча аңлатмалар бирергә;

күзәтү органыннан, аның вазифалы шәхесләреннән тикшерү фәненә кагыла торган мәгълүматны һәм Русия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары белән шул мәгълүматны бирү алдан билгеләнгән мәгълүматны алырга;

документлар һәм (яисә) мәгълүмат башка дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан я дәүләт органнары яисә җирле үзидарә органнарының карамагындагы булган оешмалардан идарәара информацион үзара эш итү чикләрендә күзәтү органы белән алынган документлар һәм (яисә) мәгълүмат белән танышырга;

идарәара информацион үзара эш итү чикләрендә соралган документларны һәм (яисә) мәгълүматны үз инициатива буенча күзәтү органына китерергә;

тикшерү нәтиҗәләре белән танышырга һәм тикшерү актында тикшерү нәтиҗәләре белән танышу, аларга риза яисә риза булмау турында, шулай да күзәтү органының аерым вазифалы шәхесләрнең гамәлләре белән танышу турында билгеләргә;

тикшерүне үткәргәндә күзәтү объектының хокукларын бозуга китергән күзәтү органының вазифалы шәхесләрнең карарларын һәм гамәлләрен (бер нәрсә дә эшләмәгәнен) административ һәм (яисә) суд тәртибендә Русия Федерациясе законнарына туры китереп шикаять бирергә;

эшмәкәр хокукларын яклау буенча Русия Федерациясе Президенты карамагындагы вәкилне я Татарстан Республикасында эшмәкәр хокукларын яклау буенча вәкилне тикшерүдә катнаштырырга.

8. Күзәтү объектының җитәкчесе, башка вазифалы шәхесе яисә вәкаләтле вәкиле бурычлы:

күзәтү органының вазифалы шәхесләренә күзәтү объектының территориясенә, биналарына һәм башка хезмәт бүлмәләренә киртәсез керүне тәэмин итәргә;

әгәр билгеләнгән документлар һәм мәгълүмат тикшерү фәне белән бәйле булса һәм билгеләнгән документларны һәм мәгълүматны идарәара информацион үзара эш итү чикләрендә сорап алырга мөмкинлек булмаса, билгеләп куелган сроклар эчендә тикшерүне үткәрер өчен кирәк булган

документларны һәм мәгълүматны күзәтү органының вазифалы шәхесләренә китерүне тәэмин итәргә;

дәлилләнгән запросны алган көннән бирле ун эш көне эчендә юридик шәхес, индивидуаль эшмәкәр запроста билгеләнгән документларны күзәтү органына җибәрергә бурычлы;

халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген үзенчәлектәге гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә мәҗбүри таләпләрне башкару буенча чараларны оештыру һәм үткәрү өчен күзәтү объектының җаваплы җитәкчеләре, башка вазифалы шәхесләре яисә вәкаләтле вәкилләре булуны тәэмин итәргә.

Дәүләт функциясен башкару нәтиҗәсе

9. Дәүләт функциясен башкаруның нәтиҗәсе халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген үзенчәлектәге гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә күзәтү объектлары таләпләрне үтәгәнен тикшерү нәтиҗәләре буенча чараларны күрү булып тора.

Региональ дәүләт күзәтүне тормышка ашыру нәтиҗәсе түбәндәгеләр булып тора:

тикшерү акты;

тикшерүләрне исәпләү журналында (ул булганда) үткәрелгән күчмә тикшерү турында язу;

№ 294-ФЗ Федераль законының 13.3 статьясына һәм № 415 РФ Хөкүмәте карарына туры китереп бердәм тикшерүләр реестрына кертелгән мәгълүмат;

мәҗбүри таләпләрне бозулары табылган очракта:

күзәтү объекты ягына административ җинаять турында протокол;

табылган бозуларны бетерү турында аларны башкару срогын билгеләп язылган күзәтү объектына бирелгән кушу.

10. Әгәр дәүләт функциясен башкару өчен күзәтү органына гражданнарның, шул исәптән индивидуаль эшмәкәрләрнең, юридик шәхесләрнең, мөрәҗәгатьләре һәм гаризалары, дәүләт хакимияте органнарыннан, бирле үзидарә органнарыннан, массакүләм мәгълүмат чараларыннан мәгълүмат килү нигез булган очракта дәүләт функциясен башкару нәтиҗәләре буенча “Русия Федерациясе гражданнарының мөрәҗәгатьләрен карап тикшерү тәртибе турында” 02.05.2006 № 59-ФЗ Федераль законы белән билгеләп куелган тәртиптә гариза бирүчегә җавап җибәрелә.

II. Дәүләт функциясен башкару тәртибенә таләпләр

Дәүләт функциясен башкару турында белдерү тәртибе.

11. Күзәтү органының булган урыны: Казан шәһәре, Ак. Губкин ур., 50.

12. Күзәтү органына документларны һәм региональ дәүләт күзәтүне башкару сораулары буенча мөрәҗәгатьләрне җибәрер өчен почта адресы: 420088, Казан шәһәре, Ак. Губкин ур., 50.

13. Күзәтү органының белешмәләр телефоны: (843) 221-62-23.

“Интернет” информацион-телекоммуникацион челтәрдә күзәтү органының рәсми сайт адресы – www.mchs.tatarstan.ru, электрон почта адресы: mchsrt@tatar.ru.

14. Дәүләт функциясен башкару сораулары буенча мәгълүмат, дәүләт функциясен башкару барышы турында белешмәләр кызыксынган шәхесләргә китерелә:

телдән мөрәҗәгать итү буенча (шәхси я телефон аша);

язу мөрәҗәгать итү буенча;

электрон почта буенча;

күзәтү органының рәсми сайтын, “Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль уңайлыклары порталы” (http://uslugi@tatar.ru) (алга таба – Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль уңайлыклары порталы) Татарстан Республикасы дәүләт информацион системасын кулланып электрон килеш җибәреп;

күзәтү органының бүлмәсендә информацион стендта.

Телдән мөрәҗәгать итүгә җавап кичектермичә мөрәҗәгать иткәннән соң бирелә, язу мөрәҗәгать итүгә һәм (яисә) электрон почта буенча мөрәҗәгать итүгә җавап мөрәҗәгать итүдә язылган адреска яисә электрон адреска күзәтү органында бирелгәге мөрәҗәгать итү теркәлүе вакытыннан алып 30 көннән артык булмаган срок эчендә җибәрелә.

Чакыруга җавап иткән күзәтү органының вазифалы шәхесе бирелгән сорауларга үзе җавап бирә алмаса, телефон чакыруы башка вазифалы шәхескә адреслауланырга (күчерелергә) тиеш яисә мөрәҗәгать иткәнгә кирәк мәгълүматны алып була торган телефон номеры әйтелергә тиеш.

15. Күзәтү органының рәсми сайтында, Татарстан Республикасы дәүләт муниципаль уңайлыклары порталында, күзәтү органының бүлмәсендә информацион стендта түбәндәге мәгълүмат урнаштырыла:

дәүләт функциясен башкару тәртибенә кагыла торган Русия Федерациясе законнарының һәм Татарстан Республикасы законнарының төп кагыйдәләре турында;

биредәге Регламент (күзәтү органының бүлмәсендә информацион стендта биредәге Регламентның аерым текст өзекләре урнаштырыла);

министр әмере белән расланган еллык планлы тикшерүләрне үткәрү планы (алга таба – план);

күзәтү органының һәм дәүләт күзәтү органнарының булган урыны, эш графигы, телефон һәм факс номерлары, электрон почта адресы;

дәүләт функциясен башкарганда тормышка ашырыла торган (кабул ителгән) гамәлләргә (бер нәрсә дә эшләмәүгә) һәм карарларга риза булмыйча шикаять бирү тәртибе;

дәүләт функциясен башкарганда гамәлләрнең эзлеклелеген күрсәтә торган блок-схема.

## Күзәтү органнарының эш тәртибе

16. Күзәтү органы өчен (җирле вакыт буенча) 13.00 алып 13.45 кадәр төшке ашка тәнәфес белән алдагы эш графигы (режимы) билгеләп куела:

дүшәмбе 9.00 - 18.00

сишәмбе 9.00 - 18.00
чәршәмбе 9.00 - 18.00
пәнҗешәмбе 9.00 - 18.00
җомга 9.00 - 16.45

17. Бәйрәм алды көннәрдә күзәтү органының эш вакыты озынлыгы 1 сәгатькә кыскара.

18. Күзәтү объектыннан региональ дәүләт күзәтү буенча чараларны үткәрү өчен түләү алуны булдырмау.

Региональ дәүләт күзәтү буенча чараларны үткәргән өчен, шул исәптән тикшерүләргә катнаштырылган очракларда экспертлар һәм эксперт оешмаларының уңайлыклары өчен, күзәтү объектларыннан түләү алынмый.

Шәхескә күзәтү буенча чаралар үткәрелгәндә шәхестән түләү күләме алыну турында белешмәләр

18. Күзәтү органы дәүләт функциясен түләүсез нигездә башкара.

Дәүләт функциясен башкару срогы

19. Документаль дә, күчмә дә тикшерүне үткәрүнең срогы (тикшерү башлануы датасыннан алып тикшерү нәтиҗәләре буенча актны төзү датасына кадәр) 20 эш көненнән артыграк була алмый.

Бер кече эшмәкәрлек субъекты ягына планлы күчмә тикшерүнең гомуми үткәрү срогы елга кече предприятие өчен 50 сәгатьтән һәм микропредприятие өчен 15 сәгатьтән артыграк була алмый.

Биредәге пунктның 2 нче абзацта билгеләнгән тикшерүне үткәргәндә идарәара информацион үзара эш итү чикләрендә документларны һәм (яисә) мәгълүматны алырга кирәк булган очракта тикшерүне үткәрү министр (министр урынбасары) белән идарәара информацион үзара эш итүне башкарыр өчен кирәк булган срокка туктатылырга мөмкин, ләкин ун эш көненнән артык түгел. Тикшерүне үткәрүне кабат туктату ярамый.

Тикшерүне үткәрү туктату срогы гамәлдә булганда кече эшмәкәрлек субъектының территориясендә, биналарында, төзелешләрендә, корылышларында, башка объектларында күзәтү органының билгеләнгән тикшерү белән бәйле эшләре туктатыла.

20. Авыр һәм (яисә) озак тикшеренүләр, сынаулар, махсус экспертизалар һәм расследованиеләр үткәрү кирәге белән бәйле гадәттән тыш очракларда планлы күчмә тикшерүне үткәрә торган күзәтү органының вазифалы шәхесләрнең дәлилләнгән тәкъдимнәре нигезендә министр планлы күчмә тикшерүне үткәрү срогын озайта ала, әмма 20 эш көненнән артыграк түгел, кече предприятие өчен 50 сәгатьтән һәм микропредприятие өчен 15 сәгатьтән артыграк түгел.

21. Күзәтү объектларының планлы тикшерүләре өч елга бер мәртәбәдән ешрак түгел үткәрелә (җирле үзидарә органнары һәм җирле үзидарә вазифалы шәхесләре тарафына ике елга бер мәртәбәдән ешрак түгел).

Тикшерүләрне үткәрү өчен нигезләр

22. Планлы тикшерүләр күзәтү органы белән эшкәртелә торган еллык тикшерүләр планнары нигезендә үткәреләләр.

Юридик шәхесләрнең, индивидуаль эшмәкәрләрнең планлы тикшерүләрен еллык үткәрү планы (алга таба – еллык тикшерү планы) күзәтү органы белән эшкәртелә һәм № 294-ФЗ Федераль законына туры китереп прокуратура органнары белән ризалана.

Җирле үзидарә органнарын һәм җирле үзидарә вазифалы шәхесләренең планлы тикшерүләрен үткәрүнең еллык планы (алга таба – еллык ҖҮО тикшерү планы) № 222 Русия Генпрокуратура боерыгы белән билгеләнгән тәртиптә прокуратура органнарында формалаштырыла һәм ризалана.

Планлы тикшерүләрне үткәрү елы алдыннан булган елның 1 сентябренә кадәр күзәтү органы планлы тикшерүләрне үткәрү буенча еллык план проектларын (алга таба – Планнар) прокуратура органнарына җибәрә.

Планлы тикшерүне юридик шәхесләрнең, индивидуаль эшмәкәрләрнең еллык планлы тикшерүенә кертү өчен нигез түбәндәге көннәрдән алып өч көн үтеп киткәч булып тора:

1) юридик шәхеснең, индивидуаль эшмәкәрнең дәүләт теркәүе;

2) юридик шәхеснең, индивидуаль эшмәкәрнең соңгы планлы тикшерүне үткәрүне тәмамы;

3) туры килгән өлкәдә Русия Федерациясе Хөкүмәте белән вәкаләт бирелгән башкарма хакимиятенең федераль органына эшмәкәр эшенең аерым төрләрен тормышка ашыру башлануы турында тапшырылган белдерүгә туры китереп билгеләнгән белдерүне таләп итә торган эшләр башкарылган яисә уңайлыклар күрсәтелгән очракта юридик шәхес, индивидуаль эшмәкәр эшмәкәрле эшне тормышка ашыру башлануы.

23. Планлы тикшерүне еллык ҖҮО тикшерү планына кертү өчен нигез түбәндәгеләрнең көненнән бирле ике ел үтү нигез булып тора:

1) җирле үзидарә органын юридик шәхес буларак дәүләт теркәүе;

2) җирле үзидарә органының яисә җирле үзидарә вазифалы шәхеснең соңгы планлы тикшерүенең тәмамы.

Еллык тикшерүләрне үткәрү планы № 489 Русия Федерациясе Хөкүмәте карары белән расланган форма буенча төзелә.

Еллык ҖҮО тикшерү планының формасы № 222 Русия Генпрокуратурасы боерыгы белән расланган.

Күзәтү объектларының еллык тикшерүләрне үткәрү планы министр белән раслана.

Расланган еллык планлы тикшерүләрне үткәрү планнары тикшерү елы алдыннан бара торган елның 1 нче ноябреннән соңрак түгел күзәтү органының рәсми сайтында аларны урнаштыру аша, я башка мөмкин юл белән кызыксынган шәхесләргә җиткерелә.

2018 елның 31 нче декабренә кадәр "Русия Федерациясендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү турында" 2007 ел 24 нче июль № 209-ФЗ Федераль законының 4 нче статьясының кагыйдәләренә туры китереп кече эшмәкәрлек субъектлары булып исәпләнгән юридик шәхесләрнең һәм индивидуаль

эшмәкәрләрнең тарафына планлы тикшерүләр № 294-ФЗ Федераль законының 26.1 статьясының таләпләренә туры китереп оештырыла һәм үткәрелә.

24. Планнан тыш тикшерүне үткәрер өчен нигезләр:

күзәтү объекты белән элек бирелгән мәҗбүри таләпләр бозуын бетерү турында кушуны башкару срогы үтү;

түбәндәге фактлар турында күзәтү органына гражданнарның, шул исәптән индивидуаль эшмәкәрләрдән, юридик шәхесләрдән мөрәҗәгать итүләре һәм гаризалары, дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, массакүләм мәгълүмат чараларыннан мәгълүмат килүе:

а) гражданнарның гомеренә, сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирә мохитка, Русия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарих һәм мәдәният памятникларына), дәүләт иминлегенә зыян китерү янауы, шулай да табигый һәм техноген үзенчәлекле гадәттән тыш хәлләр янауы килеп чыгу;

б) гражданнарның гомеренә, сәламәтлегенә зыян китерү, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирә мохитка, Русия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарих һәм мәдәният памятникларына), дәүләт иминлегенә зыян китерү, шулай да табигый һәм техноген үзенчәлекле гадәттән тыш хәлләр килеп чыгу;

в) кулланучылар хокукларын бозу (хокуклары бозылган гражданнар мөрәҗәгать иткән очракта);

г) Русия Федерациясе Президенты, Русия Федерациясе Хөкүмәте йөкләмәләренә туры китереп чыгарылган һәм прокуратура органнарына килгән материаллар һәм мөрәҗәгать итүләр буенча законнарны башкару артыннан региональ дәүләт күзәтү чикләрендә планнан тыш тикшерүне үткәрү турында прокурорның таләбе нигезендә булган күзәтү органының әмере.

Җирле үзидарә органының һәм җирле үзидарә вазифалы шәхесләренең планнан тыш тикшерүен үткәрер өчен нигез булып тора:

1) күзәтү органына гражданнардан, юридик шәхесләрдән мөрәҗәгатьләр һәм гадәттән тыш хәлләргә, гражданнарның гомеренә һәм сәламәтлегенә хәвеф, шулай да гражданнарның массакүләм хокук бозуларына китерә торган Русия Федерациясе законнарын бозу фактлары турында дәүләт органнарыннан мәгълүмат килү;

2) Русия Федерациясе Президенты, Русия Федерациясе Хөкүмәте кушуларына туры китереп һәм Русия Федерациясе Генераль прокурорының, Русия Федерациясе субъекты прокурорының таләбе нигезендә прокуратура органнарына килгән материаллар һәм мөрәҗәгатьләр буенча законнарны үтәү артыннан күзәтү чикләрендә планнан тыш тикшерүне үткәрү турында министрның (министр урынбасарының) карары.

Күзәтү органына мөрәҗәгать иткән шәхесне ачыклата алмый торган мөрәҗәгать итүләр һәм гаризалар, шулай да биредәге пунктта билгеләнгән фактлар турында белешмәләрне тотмый торган мөрәҗәгать итүләр һәм гаризалар планнан тыш тикшерүне үткәрер өчен нигез була алмый.

Биредәге пунктның “а” һәм “б” пункт асларында билгеләнгән нигезләр буенча күзәтү объектының планнан тыш күчмә тикшерүе шундый күзәтү объектының эшен тормышка ашыру урыны буенча прокуратура органы белән ризалаганнан соң күзәтү органы белән үткәрелергә мөмкин.

Күзәтү органы күзәтү объектының планнан тыш күчмә тикшерүен прокуратура органы белән ризалау турында гариза 30.04.2009 № 141 РФ Икътисадый үсеш министрлыгы боерыгы белән расланган типовой формага туры китереп рәсмиләштерелә.

25. Турыдан-туры региональ дәүләт күзәтүне тормышка ашыра торган вазифалы шәхесләр.

Күзәтү органының региональ дәүләт күзәтүне тормышка ашыра торган вазифалы шәхесләре исемлеге Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты белән раслана.

26. № 294-ФЗ Федераль законын бозу өчен юридик шәхесләрнең, индивидуаль эшмәкәрләрнең җаваплылыгы.

№ 294-ФЗ Федераль законын бозуын булдырган, нигезсез тикшерүләрне үткәрүгә комачаулый торган, тикшерүләрне үткәрүдән кача торган һәм (яисә) билгеләп куелган срок эчендә табылган мәҗбүри таләпләрне бозуларын бетерү турында күзәтү органының кушуларын башкармый торган юридик шәхесләр, аларның җитәкчеләре, башка вазифалы шәхесләре яисә юридик шәхесләрнең вәкилләре, индивидуаль эшмәкәрләр, аларның вәкаләтле вәкилләре Русия Федерациясе законнары туры китереп җаваплы.

27. Тикшерүне үткәргәндә күзәтү органының, аның вазифалы шәхесләренең җаваплылыгы.

Күзәтү органы, аның вазифалы шәхесләре тикшерүне үткәргәндә функцияләрен, хезмәт бурычларын тиешле рәвешендә башкармаган, хокукка каршы гамәлләрне эшләгән (бер нәрсә дә эшләмәү) очракта Русия Федерациясе законнарына туры китереп җаваплы.

Күзәтү органы Русия Федерациясе законнарын бозуда гаепле булган вазифалы шәхесләр ягына кабул ителгән чаралар турында хокуклары һәм (яисә) законлы кызыксынулары бозылган юридик шәхескә, индивидуаль эшмәкәргә шундый чараларны кабул итү көненнән алып ун көн эчендә язу формасында хәбәр итәргә бурычлы.

## III. Күзәтү объектларына йөкләнгән мәҗбүри таләпләр

Күзәтү объектларына йөкләнгән мәҗбүри таләпләр, шул таләпләрне билгеләп куя торган норматив хокук актлар, шулай да күзәтү объектлары күрсәтә торган документлар исемлеге 1 нче таблицада күрсәтелгән.

1 нче таблица. Күзәтү объектларына салынган мәҗбүри таләпләр исемлеге

| Күзәтү объектлары | Тикшерелә торган таләп | Мәҗбүри таләпне билгеләп куя торган норматив хокук акт |
|---|---|---|
| Җирле үзидарә органнары | 1. Муниципаль районның, шәһәр округының, шәһәр торагының Гадәттән тыш хәлләр бетерүнең бердәм дәүләт системасының территориаль система асты звеносының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү һәм янгын иминлеген тәэмин итү буенча комиссиясен (алга таба – РСЧС) кору. | “Русия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыру буенча гомуми принциплар турында” 2003 ел 6 нчы октябрь № 131-ФЗ Федераль законының 14 нче статьясы 1 нче пункты 8 нче пункт асты, 15 нче статьясы 1 нче пункты 7 нче пункт асты, 16 нче статьясы 1 нче пункты 8 нче пункт асты;<br>“Гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча бердәм дәүләт системасы турында” 2003 ел 30 нчы декабрь № 794 Русия Федерациясе Хөкүмәте карары белән расланган Гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча бердәм дәүләт системасы турында кагыйдәнамәнең (алга таба – РСЧС турында Кагыйдәнамә) 7 нче пункты |
| | 2. Муниципаль районның, шәһәр округының, шәһәр торагының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү һәм янгын иминлеген тәэмин итү буенча гамәлләр планы. | “Халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген үзенчәлектәге гадәттән тыш хәлләрдән саклау турында” 1994 ел 21 нче декабрь № 68-ФЗ Федераль законының 14 нче статьясы “д” пункт асты. |
| | 3. Сугыш һәм тынычлык | “Халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген |

| | | |
|---|---|---|
| | вакытында гадәттән тыш хәлләрне бетерер өчен материаль-техник һәм финанс резервларны кору һәм тоту. | үзенчәлектәге гадәттән тыш хәлләрдән саклау турында” 1994 ел 21 нче декабрь № 68-ФЗ Федераль законының 11 нче статьясы 2 нче пункты “д” пункт асты;<br>РСЧС турында Кагыйдәнамәнең 20 нче пункты;<br>“Табигый һәм техноген үзенчәлекле гадәттән тыш хәлләрне бетерер өчен материаль ресурс резервларын кору һәм куллану тәртибе турында” 1996 10 нчы ноябрь № 1340 Русия Федерациясе Хөкүмәте карары. |
| | 4. Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә чараларны финанслау. | “Халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген үзенчәлектәге гадәттән тыш хәлләрдән саклау турында” 1994 ел 21 нче декабрь № 68-ФЗ Федераль законының 11 нче статьясы 2 нче пункты “г” пункт асты. |
| | 5. Территориянең иминлек паспортын эшкәртү һәм раслау. | “Русия Федерациясе субъектларының һәм муниципаль берәмлекләрнең типовой иминлек паспортын раслау турында” 2004 ел 25 нче октябрь № 484 РФ ГТХМ боерыгы. |
| | 6. Гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә җирле үзидарә органнарының вазифалы шәхесләрен һәм халыкны хәзерләү. | “Халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген үзенчәлектәге гадәттән тыш хәлләрдән саклау турында” 1994 ел 21 нче декабрь № 68-ФЗ Федераль законының 11 нче статьясы 2 нче пункты “а” пункт асты;<br>“Табигый һәм техноген үзенчәлектәге гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә халыкны хәзерләү турында” 2003 ел 4 нче сентябрь № 547 Русия Федерациясе Хөкүмәте карары;<br>“Русия ГТХМ ның белем бирү учреждениеләрендә, федераль башкару хакимияте органнарының һәм оешмаларның өстәмә профессиональ белем бирү учреждениеләрендә, РФ субъектларының |

| | | |
|---|---|---|
| | | гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр буенча уку-методика үзәкләрендә (алга таба – ГО һәм ЧС буенча УМЦ) һәм муниципаль берәмлекләренең гражданнар оборонасы курсларында яңадан укытуны яисә квалификацияне күтәрүне үтә торган вәкаләтле эшчеләрнең исемлеген раслау турында” 2004 ел 19 нче гыйнвар № 19 РФ ГТХМ боерыгы. |
| | 7. Шәһәр округының, шәһәр торагының халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклар өчен кирәк булган көчләрен һәм чараларын кору, хәзерләү һәм әзер тоту. | “Русия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыру буенча гомуми принциплар турында” 2003 ел 6 нчы октябрь № 131-ФЗ Федераль законының 14 нче статьясы 1 нче пункты 24 нче пункт асты, 16 нчы статьясы 1 нче пункты 29 нчы пункт асты. |
| | 8. Җирле үзидарә органы карамагында халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау өчен махсус вәкаләт бирелгән һәм һәрвакыт гамәлдә булган идарә итүче органны кору. | “Гражданнар оборонасы өлкәсендә мәсьәләләрне хәл итәр өчен оешмаларда вәкаләт бирелгән структура бүлекчәләрен (эшчеләрне) кору (билгеләү) турында” 1999 ел 10 нчы июль № 782 Русия Федерациясе Хөкүмәте карары;<br>РСЧС турында Кагыйдәнамәнең 10 нчы пункты. |
| | 9. Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә чараларны үткәрү буенча өйрәнүләрне һәм күнегүләрне үткәрү. | “Гражданнар оборонасы буенча өйрәнүләрне һәм күнегүләрне хәзерләү һәм үткәрү, халыкны гадәттән тыш хәлләрдән саклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләрнең иминлеген тәэмин итү буенча инструкцияләрне раслау турында” 2013 ел 24 нче апрель № 284 РФ ГТХМ боерыгы;<br>“Табигый һәм техноген үзенчәлектәге гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә халыкны хәзерләү турында” 2003 ел 4 нче сентябрь |

| | | |
|---|---|---|
| | | № 547 Русия Федерациясе Хөкүмәте карары. |
| | 10. Халыкны гадәттән тыш хәлләр турында белдереп торуны оештыру, халыкка гадәттән тыш хәлләр турында хәбәр итү һәм аны белдереп тору буенча муниципаль системаларын даими әзерлектә тоту. | “Халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген үзенчәлектәге гадәттән тыш хәлләрдән саклау турында” 1994 ел 21 нче декабрь № 68-ФЗ Федераль законының 11 нче статьясы 2 нче пункты “м” пункт асты;<br>“Халыкны белдерү системалары турында кагыйдәнамәне раслау тырында” 2006 ел 25 нче июль № 422/90/376 РФ ГТХМ / РФ Элемтә министрлыгы / РФ Мәдәният министрлыгы бердәм боерыгы. |
| | 11. Бердәм “112” номеры буенча ашыгыч оператив хезмәтләрне чакыру системасын кору, куллану һәм үстерү буенча чараларны башкару. | “Халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген үзенчәлектәге гадәттән тыш хәлләрдән саклау турында” 1994 ел 21 нче декабрь № 68-ФЗ Федераль законының 11 нче статьясы 2 нче пункты “л” пункт асты. |
| | 12. Гадәттән тыш хәл килеп чыкканда оешманың вазифалы шәхесләренә (КЧС ПБ члennарына) хәбәр итү һәм гадәттән тыш хәлне бетерер өчен көчләрне һәм чараларны әзер рәвешенә китерү. | “Халыкны белдерү системалары турында кагыйдәнамәне раслау тырында” 2006 ел 25 нче июль № 422/90/376 РФ ГТХМ / РФ Элемтә министрлыгы / РФ Мәдәният министрлыгы бердәм боерыгы. |
| | 13. Муниципаль берәмлекнең нефть һәм | “Русия Федерациясе территориясендә авария нәтиҗәсе буларак нефть һәм нефть продуктлары түгелүен кисәтү һәм бетерү буенча |

| | | |
|---|---|---|
| | нефть продуктлары түгелүен кисәтү һәм бетерү буенча эшкәртелгән, ризаланган һәм расланган планның (ПЛАРН) булуы. | кичектергесез чаралар турында” 2000 ел 21 нче август № 613 Русия Федерациясе Хөкүмәте карары;<br>“Русия Федерациясе территориясендә нефть һәм нефть продуктлары түгелүен кисәтү һәм бетерү буенча чараларны оештыру тәртибе турында” 2002 ел 15 нче февраль № 240 Русия Федерациясе Хөкүмәте карары;<br>“Русия Федерациясе территориясендә нефть һәм нефть продуктлары түгелүен кисәтү һәм бетерү буенча планнарны эшкәртү һәм ризалау кагыйдәләрен раслау турында” 2004 ел 28 нче декабрь № 621 Русия ГТХМ боерыгы. |
| | 14. Табигый һәм техноген үзенчәлектәге гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә эшкәртелгән һәм расланган норматив хокук актлары булуы. | Халык тормышы иминлеген тәэмин итү өлкәсендә мөнәсәбәтләрне көйли торган муниципаль хокук базасын эшкәртү буенча шәһәр округларының җирле үзидарә органнарының җитәкчеләре өчен белешмә-методик ярдәмлек. Русия ГТХМ. М.: ФГБУ ВНИИ ГОЧС (ФЦ), 2013,  184 бит;<br>Халык тормышы иминлеген тәэмин итү өлкәсендә мөнәсәбәтләрне көйли торган муниципаль хокук базасын эшкәртү буенча муниципаль районнарының җирле үзидарә органнарының җитәкчеләре өчен белешмә-методик ярдәмлек. Русия ГТХМ. М.: ФГБУ ВНИИ ГОЧС (ФЦ), 2013,  144 бит;<br>Халык тормышы иминлеген тәэмин итү өлкәсендә мөнәсәбәтләрне көйли торган муниципаль хокук базасын эшкәртү буенча шәһәр торакларының җирле үзидарә органнарының җитәкчеләре өчен белешмә-методик ярдәмлек. Русия ГТХМ. М.: ФГБУ ВНИИ ГОЧС (ФЦ), 2013,  183 бит. |
| Гадәттән тыш хәлләрне кисәтер | 1. Оешманың Гадәттән тыш хәлләр һәм янгын иминлеген | РСЧС турында Кагыйдәнамәнең 7 нче пункты. |

| | | |
|---|---|---|
| һәм бетерер өчен көчләрне һәм чараларны кора торган һәм бердәм системаның территориаль система астының звенолары составына керә торган оешмалар | тәэмин итү буенча комиссияне кору. | |
| | 2. Оешманың гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча гамәлләр планы. | “Халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген үзенчәлектәге гадәттән тыш хәлләрдән саклау турында” 1994 ел 21 нче декабрь № 68-ФЗ Федераль законының 11 нче статьясы “а” пункт асты. |
| | 3. Сугыш һәм тынычлык вакытында гадәттән тыш хәлләрне бетерер өчен материаль-техник һәм финанс резервларны кору һәм тоту. | “Халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген үзенчәлектәге гадәттән тыш хәлләрдән саклау турында” 1994 ел 21 нче декабрь № 68-ФЗ Федераль законының 14 нче статьясы “ж” пункт асты;<br>“Табигый һәм техноген үзенчәлекле гадәттән тыш хәлләрне бетерер өчен материаль ресурс резервларын кору һәм куллану тәртибе турында” 1996 10 нчы ноябрь № 1340 Русия Федерациясе Хөкүмәте карары. |
| | 4. Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә чараларны финанслау. | “Халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген үзенчәлектәге гадәттән тыш хәлләрдән саклау турында” 1994 ел 21 нче декабрь № 68-ФЗ Федераль законының 14 нче статьясы “е” пункт асты. |

| | | |
|---|---|---|
| | | |
| | 5. Гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә оешмаларның вазифалы шәхесләрен хәзерләү. | “Халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген үзенчәлектәге гадәттән тыш хәлләрдән саклау турында” 1994 ел 21 нче декабрь № 68-ФЗ Федераль законының 14 нче статьясы “в” пункт асты;<br>“Табигый һәм техноген үзенчәлектәге гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә халыкны хәзерләү турында” 2003 ел 4 нче сентябрь № 547 Русия Федерациясе Хөкүмәте карары;<br>“Русия ГТХМ ның белем бирү учреждениеләрендә, федераль башкару хакимияте органнарының һәм оешмаларның өстәмә профессиональ белем бирү учреждениеләрендә, РФ субъектларының ГО һәм ЧС буенча УМЦ һәм муниципаль берәмлекләренең гражданнар оборонасы курсларында яңадан укытуны яисә квалификацияне күтәрүне үтә торган вәкаләтле эшчеләрнең исемлеген раслау турында” 2004 ел 19 нче гыйнвар № 19 РФ ГТХМ боерыгы. |
| | 6. Предприятие персоналын, халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклар өчен кирәк булган көчләрне һәм чараларны кору, хәзерләү һәм әзер рәвештә тоту. | “Халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген үзенчәлектәге гадәттән тыш хәлләрдән саклау турында” 1994 ел 21 нче декабрь № 68-ФЗ Федераль законының 14 нче статьясы;<br>“Хәвеф җитештерү объектларының сәнәгый иминлеге турында” 1997 ел 21 нче июль № 116-ФЗ Федераль законының 10 нчы статьясы;<br>“Авария-коткару хезмәтләре һәм коткаручылар статусы турында” 1995 ел 22 нче август № 151-ФЗ Федераль законының 7 нче, 12 нче статьялары. |
| | 7. Халыкны һәм территорияләрне гадәттән | “Гражданнар оборонасы өлкәсендә мәсьәләләрне хәл итәр өчен оешмаларда вәкаләт бирелгән структура бүлекчәләрен (эшчеләрне) |

| | | |
|---|---|---|
| | тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә мәсьәләләрне хәл итәр өчен вәкаләт бирелгән махсус вазифалы шәхесне оешмада билгеләү. | кору (билгеләү) турында” 1999 ел 10 нчы июль № 782 Русия Федерациясе Хөкүмәте карары;<br>РСЧС турында Кагыйдәнамәнең 10 нчы пункты. |
| | 8. Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә чараларны үткәрү буенча өйрәнүләрне һәм күнегүләрне үткәрү. | “Гражданнар оборонасы буенча өйрәнүләрне һәм күнегүләрне хәзерләү һәм үткәрү, халыкны гадәттән тыш хәлләрдән саклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләрнең иминлеген тәэмин итү буенча инструкцияләрне раслау турында” 2013 ел 24 нче апрель № 284 РФ ГТХМ боерыгы;<br>“Табигый һәм техноген үзенчәлектәге гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә халыкны хәзерләү турында” 2003 ел 4 нче сентябрь № 547 Русия Федерациясе Хөкүмәте карары. |
| | 9. Гадәттән тыш хәл килеп чыкканда оешманың вазифалы шәхесләренә хәбәр итү һәм гадәттән тыш хәлне бетерер өчен көчләрне һәм чараларны әзер рәвешенә китерү. | “Халыкны белдерү системалары турында кагыйдәнамәне раслау тырында” 2006 ел 25 нче июль № 422/90/376 РФ ГТХМ / РФ Элемтә министрлыгы / РФ Мәдәният министрлыгы бердәм боерыгы |
| Кеше үлемнәренә, кешеләрнең сәламәтлегенә яисә әйләнә-тирә мохитка зыян, зур материаль югалышларга һәм | 1. Оешманың Гадәттән тыш хәлләр һәм янгын иминлеген тәэмин итү буенча комиссияне кору. | РСЧС турында Кагыйдәнамәнең 7 нче пункты. |

| | | |
|---|---|---|
| тормыш бозуына китерә торган гадәттән тыш хәлләрне китереп чыгара ала торган оешмалар | | |
| | 2. Оешманың гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча гамәлләр планы. | “Халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген үзенчәлектәге гадәттән тыш хәлләрдән саклау турында” 1994 ел 21 нче декабрь № 68-ФЗ Федераль законының 14 нче статьясы “а” пункт асты. |
| | 3. Сугыш һәм тынычлык вакытында гадәттән тыш хәлләрне бетерер өчен материаль-техник һәм финанс резервларны кору һәм тоту. | “Халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген үзенчәлектәге гадәттән тыш хәлләрдән саклау турында” 1994 ел 21 нче декабрь № 68-ФЗ Федераль законының 14 нче статьясы “ж” пункт асты;<br>“Табигый һәм техноген үзенчәлекле гадәттән тыш хәлләрне бетерер өчен материаль ресурс резервларын кору һәм куллану тәртибе турында” 1996 10 нчы ноябрь № 1340 Русия Федерациясе Хөкүмәте карары. |
| | 4. Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә чараларны финанслау. | “Халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген үзенчәлектәге гадәттән тыш хәлләрдән саклау турында” 1994 ел 21 нче декабрь № 68-ФЗ Федераль законының 14 нче статьясы “е” пункт асты. |
| | 5. Потенциаль хәвеф объектның иминлек | “Хәвеф объектның типовой паспортны раслау турында” 2004 ел 4 нче ноябрь № 506 Русия ГТХМ боерыгы. |

| | | |
|---|---|---|
| | паспортын эшкәртү һәм раслау. | |
| | 6. Гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә оешмаларның вазифалы шәхесләрен хәзерләү. | “Халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген үзенчәлектәге гадәттән тыш хәлләрдән саклау турында” 1994 ел 21 нче декабрь № 68-ФЗ Федераль законының 11 нче статьясы “в” пункт асты;<br>“Табигый һәм техноген үзенчәлектәге гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә халыкны хәзерләү турында” 2003 ел 4 нче сентябрь № 547 Русия Федерациясе Хөкүмәте карары;<br>“Русия ГТХМ ның белем бирү учреждениеләрендә, федераль башкару хакимияте органнарының һәм оешмаларның өстәмә профессиональ белем бирү учреждениеләрендә, РФ субъектларының ГО һәм ЧС буенча УМЦ һәм муниципаль берәмлекләренең гражданнар оборонасы курсларында яңадан укытуны яисә квалификацияне күтәрүне үтә торган вәкаләтле эшчеләрнең исемлеген раслау турында” 2004 ел 19 нче гыйнвар № 19 РФ ГТХМ боерыгы. |
| | 7. Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә мәсьәләләрне хәл итәр өчен оешмаларда вәкаләт бирелгән махсус структура бүлекчәне яисә вазифалы шәхесне кору. | “Гражданнар оборонасы өлкәсендә мәсьәләләрне хәл итәр өчен оешмаларда вәкаләт бирелгән структура бүлекчәләрен (эшчеләрне) кору (билгеләү) турында” 1999 ел 10 нчы июль № 782 Русия Федерациясе Хөкүмәте карары;<br>РСЧС турында Кагыйдәнамәнең 10 нчы пункты. |
| | 8. Халыкны һәм территорияләрне гадәттән | “Гражданнар оборонасы буенча өйрәнүләрне һәм күнегүләрне хәзерләү һәм үткәрү, халыкны гадәттән тыш хәлләрдән саклау, |

| | | |
|---|---|---|
| | тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә чараларны үткәрү буенча өйрәнүләрне һәм күнегүләрне үткәрү. | янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләрнең иминлеген тәэмин итү буенча инструкцияләрне раслау турында" 2013 ел 24 нче апрель № 284 РФ ГТХМ боерыгы;<br>"Табигый һәм техноген үзенчәлектәге гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә халыкны хәзерләү турында" 2003 ел 4 нче сентябрь № 547 Русия Федерациясе Хөкүмәте карары. |
| | 9. Хәвеф җитештерү объектының локаль белдерү системасын кору һәм әзер рәвешендә саклау. | "Гражданнар оборонасы турында" 1998 ел 12 нче февраль № 28-ФЗ Федераль законының 9 нчы статьясы 3 нче пункты;<br>"Потенциаль хәвеф объектлар районында локаль белдерү системаларын кору турында" 1993 ел 1 нче март № 178 РФ Хөкүмәте карары. |
| | 10. Оешманы, халыкны гадәттән тыш хәлләр турында белдереп торуны оештыру, халыкка гадәттән тыш хәлләр турында хәбәр итү һәм аны белдереп тору буенча системаларны даими әзерлектә тоту. | "Халыкны белдерү системалары турында кагыйдәнамәне раслау тырында" 2006 ел 25 нче июль № 422/90/376 РФ ГТХМ / РФ Элемтә министрлыгы / РФ Мәдәният министрлыгы бердәм боерыгы. |
| | 11. Оешманың (объектның) кизү-диспетчер хезмәтен кору, кулланылу һәм үстерү буенча чараларны башкару. | РСЧС турында Кагыйдәнамәнең 11 нче пункты. |
| | 12. Гадәттән тыш хәл килеп чыкканда оешманың вазифалы шәхесләренә хәбәр | "Халыкны белдерү системалары турында кагыйдәнамәне раслау тырында" 2006 ел 25 нче июль № 422/90/376 РФ ГТХМ / РФ Элемтә министрлыгы / РФ Мәдәният министрлыгы бердәм боерыгы |

| | | |
|---|---|---|
| | итү һәм гадәттән тыш хәлне бетерер өчен көчләрне һәм чараларны әзер рәвешенә китерү. | |
| | 13. Икътисад объекты документларының страховой фондын коруны раслый торган документлар булу. | “Гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча бердәм дәүләт системасын документлар белән тәэмин итәр өчен бердәм Русия документларының страховой фондын куллану турында кагыйдәнамәне раслау турында” 1996 ел 13 нче август № 971(ДСП) Русия Федерациясе Хөкүмәте карары;<br>“Хәвеф объектларга, халык тормышын тәэмин итүче системалар объектларына һәм күп кеше була торган объектларга Татарстан Республикасы документларының территориаль страховой фондын үстерү турында” 2006 ел 17 нче апрель № 173 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары;<br>“Муниципаль берәмлекләрдә һәм оешмаларда гражданнар оборонасын оештыру һәм алып бару турында кагыйдәнамәне раслау турында” 2008 ел 14 нче ноябрь № 687 Русия ГТХМ боерыгының 15.14 һәм 16.13 пунктлары. |
| | 13. Нефть һәм нефть продуктлары түгелүен кисәтү һәм бетерү буенча эшкәртелгән, ризаланган һәм расланган планы (ПЛАРН) булу<br>Чыганаклар разведкасын, нефть чыгаруын, шулай да | “Русия Федерациясе территориясендә авария нәтиҗәсе буларак нефть һәм нефть продуктлары түгелүен кисәтү һәм бетерү буенча кичектергесез чаралар турында” 2000 ел 21 нче август № 613 Русия Федерациясе Хөкүмәте карары;<br>“Русия Федерациясе территориясендә нефть һәм нефть продуктлары түгелүен кисәтү һәм бетерү буенча чараларны оештыру тәртибе турында” 2002 ел 15 нче февраль № 240 Русия Федерациясе Хөкүмәте карары; |

| | | |
|---|---|---|
| | нефтьне һәм нефть продуктларын эшкәртү, күчерү, саклау һәм куллануны башка торган милек формасыннан бәйсез оешмалар өчен. | “Русия Федерациясе территориясендә нефть һәм нефть продуктлары түгелүен кисәтү һәм бетерү буенча планнарны эшкәртү һәм ризалау кагыйдәләрен раслау турында” 2004 ел 28 нче декабрь № 621 Русия ГТХМ боерыгы. |
| | 15. Оешма эшчеләре саныннан аттестацияләнгән профессиональ яисә штатта булмаган авария-коткару хезмәтләре (ПАСС, ПАСФ) яисә формированиеләре (ПАСФ, НАСФ) булу. | “Гражданнар оборонасы турында” 1998 ел 12 нче февраль № 28-ФЗ Федераль законының 11 нчы статьясы 2 нче пункты;<br>“Халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген үзенчәлектәге гадәттән тыш хәлләрдән саклау турында” 1994 ел 21 нче декабрь № 68-ФЗ Федераль законының 14 нче статьясы;<br>“Хәвеф җитештерү объектларының сәнәгый иминлеге турында” 1997 ел 21 нче июль № 116-ФЗ Федераль законының 10 нчы статьясы;<br>“Авария-коткару хезмәтләре һәм коткаручылар статусы турында” 1995 ел 22 нче август № 151-ФЗ Федераль законының 7 нче, 12 нче статьялары. |
| | 16. Туры килә торган лицензиясе булган яисә профессиональ авария-коткару хезмәте яисә билгеләп куелган тәртиптә аттестацияләнгән формированиесе белән карап торуга төзелгән килешү булу. | “Халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген үзенчәлектәге гадәттән тыш хәлләрдән саклау турында” 1994 ел 21 нче декабрь № 68-ФЗ Федераль законының 14 нче статьясы;<br>“Хәвеф җитештерү объектларының сәнәгый иминлеге турында” 1997 ел 21 нче июль № 116-ФЗ Федераль законының 10 нчы статьясы;<br>“Авария-коткару хезмәтләре һәм коткаручылар статусы турында” 1995 ел 22 нче август № 151-ФЗ Федераль законының 7 нче, 12 нче статьялары. |
| | 17. Нефть (нефть | “Халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген |

| | | |
|---|---|---|
| | продуктлары) түгелүен бетерү буенча эшләрне башкара торган, туры килгән лицензиясе булган яисә билгеләп куелган тәртиптә аттестацияләнгән профессиональ АСФ белән карап торуга төзелгән килешү булу. | үзенчәлектәге гадәттән тыш хәлләрдән саклау турында” 1994 ел 21 нче декабрь № 68-ФЗ Федераль законының 14 нче статьясы “д” пункт асты;<br>“Хәвеф җитештерү объектларының сәнәгый иминлеге турында” 1997 ел 21 нче июль № 116-ФЗ Федераль законының 10 нчы статьясы;<br>“Авария-коткару хезмәтләре һәм коткаручылар статусы турында” 1995 ел 22 нче август № 151-ФЗ Федераль законының 7 нче, 12 нче статьялары;<br>“Русия Федерациясе территориясендә авария нәтиҗәсе буларак нефть һәм нефть продуктлары түгелүен кисәтү һәм бетерү буенча кичектергесез чаралар турында” 2000 ел 21 нче август № 613 һәм “Русия Федерациясе территориясендә нефть һәм нефть продуктлары түгелүен кисәтү һәм бетерү буенча чараларны оештыру тәртибе турында” 2002 ел 15 нче февраль № 240 Русия Федерациясе Хөкүмәте карарлары. |
| | 18. Тынычлык вакытында штат буенча предприятиенең бөтен персоналын тәэмин итү исәбеннән индивидуаль саклану чаралары (алга таба – СИЗ), фильтр тартмалары (“КД” маркасы һ. б. ш. – предприятие профиле буенча) белән сәнәгый противогазлар запаста җыелуны тәэмин итү. | “Халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген үзенчәлектәге гадәттән тыш хәлләрдән саклау турында” 1994 ел 21 нче декабрь № 68-ФЗ Федераль законының 14 нче статьясы “а”, “е” пункт аслары;<br>“Халыкны индивидуаль саклану чаралары белән тәэмин итүне оештыру турында кагыйдәнамәне раслау турында” 2014 ел 1 нче октябрь № 543 Русия ГТХМ боерыгы;<br>“Индивидуаль саклану чараларны, радиация, химия разведкасы һәм контроле әсбапларын куллану һәм тоту кагыйдәләрен раслау һәм куллануга кертү турында” 2003 ел 27 нче май № 285 Русия ГТХМ боерыгы. |

| | | |
|---|---|---|
| | 19. Муниципаль берәмлекнең (яисә объектның) тотрыклы эшләүне күтәрүе(ПУФ) буенча комиссия, тынычлык вакытына ПУФ буенча чаралар планлаштырылмаган. | “Халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген үзенчәлектәге гадәттән тыш хәлләрдән саклау турында” 1994 ел 21 нче декабрь № 68-ФЗ Федераль законының 14 нче статьясы. |
| Белем бирү һәм социаль әһәмияте учреждениеләре | 1. Оешманың гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча гамәлләр планы. | “Халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген үзенчәлектәге гадәттән тыш хәлләрдән саклау турында” 1994 ел 21 нче декабрь № 68-ФЗ Федераль законының 14 нче статьясы “а” пункт асты. |
| | 2. Гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә оешманың вазифалы шәхесләрен хәзерләү. | “Халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген үзенчәлектәге гадәттән тыш хәлләрдән саклау турында” 1994 ел 21 нче декабрь № 68-ФЗ Федераль законының 14 нче статьясы “в” пункт асты;<br>“Табигый һәм техноген үзенчәлектәге гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә халыкны хәзерләү турында” 2003 ел 4 нче сентябрь № 547 Русия Федерациясе Хөкүмәте карары;<br>“Русия ГТХМ ның белем бирү учреждениеләрендә, федераль башкару хакимияте органнарының һәм оешмаларның өстәмә профессиональ белем бирү учреждениеләрендә, РФ субъектларының ГО һәм ЧС буенча УМЦ һәм муниципаль берәмлекләренең гражданнар оборонасы курсларында яңадан укытуны яисә квалификацияне күтәрүне үтә торган вәкаләтле эшчеләрнең исемлеген раслау турында” 2004 ел 19 нче гыйнвар № 19 РФ ГТХМ |

| | | |
|---|---|---|
| | | боерыгы. |
| | 3. Гадәттән тыш хәл килеп чыкканда һәм гадәттән тыш хәлне бетерер өчен көчләрне һәм чараларны әзер рәвешенә китергәндә оешманың вазифалы шәхесләрен белдерү. | “Халыкны белдерү системалары турында кагыйдәнамәне раслау тырында” 2006 ел 25 нче июль № 422/90/376 РФ ГТХМ / РФ Элемтә министрлыгы / РФ Мәдәният министрлыгы бердәм боерыгы. |
| | 4. Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә чараларны үткәрү буенча өйрәнүләрне һәм күнегүләрне үткәрү. | “Гражданнар оборонасы буенча өйрәнүләрне һәм күнегүләрне хәзерләү һәм үткәрү, халыкны гадәттән тыш хәлләрдән саклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләрнең иминлеген тәэмин итү буенча инструкцияләрне раслау турында” 2013 ел 24 нче апрель № 284 РФ ГТХМ боерыгы;<br>“Табигый һәм техноген үзенчәлектәге гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә халыкны хәзерләү турында” 2003 ел 4 нче сентябрь № 547 Русия Федерациясе Хөкүмәте карары. |
| | 5. Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә мәсьәләләрне чишәр өчен махсус вәкаләт бирелгән вазифалы шәхесне оешмада билгеләү. | “Гражданнар оборонасы өлкәсендә мәсьәләләрне хәл итәр өчен оешмаларда вәкаләт бирелгән структура бүлекчәләрен (эшчеләрне) кору (билгеләү) турында” 1999 ел 10 нчы июль № 782 Русия Федерациясе Хөкүмәте карары;<br>РСЧС турында Кагыйдәнамәнең 10 нчы пункты. |
| | 6. Икътисад объекты документларының страховой фондын коруны раслый | “Гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча бердәм дәүләт системасын документлар белән тәэмин итәр өчен бердәм Русия документларының страховой фондын куллану турында |

| | | |
|---|---|---|
| | торган документлар булу. | кагыйдәнамәне раслау турында” 1996 ел 13 нче август № 971(ДСП) Русия Федерациясе Хөкүмәте карары;<br>“Хәвеф объектларга, халык тормышын тәэмин итүче системалар объектларына һәм күп кеше була торган объектларга Татарстан Республикасы документларының территориаль страховой фондын үстерү турында” 2006 ел 17 нче апрель № 173 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары;<br>“Муниципаль берәмлекләрдә һәм оешмаларда гражданнар оборонасын оештыру һәм алып бару турында кагыйдәнамәне раслау турында” 2008 ел 14 нче ноябрь № 687 Русия ГТХМ боерыгының 15.14. һәм 16.13 пунктлары. |
| Балалар ялын оештыручы һәм аларны сәламәтләндерү учреждениеләре | 1. Гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә оешманың вазифалы шәхесләрен хәзерләү. | “Халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген үзенчәлектәге гадәттән тыш хәлләрдән саклау турында” 1994 ел 21 нче декабрь № 68-ФЗ Федераль законының 11 нче статьясы “в” пункт асты;<br>“Табигый һәм техноген үзенчәлектәге гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә халыкны хәзерләү турында” 2003 ел 4 нче сентябрь № 547 Русия Федерациясе Хөкүмәте карары;<br>“Русия ГТХМ ның белем бирү учреждениеләрендә, федераль башкару хакимияте органнарының һәм оешмаларның өстәмә профессиональ белем бирү учреждениеләрендә, РФ субъектларының ГО һәм ЧС буенча УМЦ һәм муниципаль берәмлекләренең гражданнар оборонасы курсларында яңадан укытуны яисә квалификацияне күтәрүне үтә торган вәкаләтле эшчеләрнең исемлеген раслау турында” 2004 ел 19 нче гыйнвар № 19 РФ ГТХМ боерыгы. |
| | 2. Гадәттән тыш хәл килеп | “Халыкны белдерү системалары турында кагыйдәнамәне раслау |

| | | |
| --- | --- | --- |
| | чыкканда һәм гадәттән тыш хәлне бетерер өчен көчләрне һәм чараларны әзер рәвешенә китергәндә оешманың вазифалы шәхесләрен белдерү. | тырында” 2006 ел 25 нче июль № 422/90/376 РФ ГТХМ / РФ Элемтә министрлыгы / РФ Мәдәният министрлыгы бердәм боерыгы. |
| | 3. Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә чараларны үткәрү буенча өйрәнүләрне һәм күнегүләрне үткәрү. | “Гражданнар оборонасы буенча өйрәнүләрне һәм күнегүләрне хәзерләү һәм үткәрү, халыкны гадәттән тыш хәлләрдән саклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләрнең иминлеген тәэмин итү буенча инструкцияләрне раслау турында” 2013 ел 24 нче апрель № 284 РФ ГТХМ боерыгы;<br>“Табигый һәм техноген үзенчәлектәге гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә халыкны хәзерләү турында” 2003 ел 4 нче сентябрь № 547 Русия Федерациясе Хөкүмәте карары. |
| | 4. Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә мәсьәләләрне чишәр өчен махсус вәкаләт бирелгән вазифалы шәхесне оешмада билгеләү. | “Гражданнар оборонасы өлкәсендә мәсьәләләрне хәл итәр өчен оешмаларда вәкаләт бирелгән структура бүлекчәләрен (эшчеләрне) кору (билгеләү) турында” 1999 ел 10 нчы июль № 782 Русия Федерациясе Хөкүмәте карары;<br>РСЧС турында Кагыйдәнамәнең 10 нчы пункты. |

## IV. Тикшерүне үткәргәндә күзәтү объектлары күрсәтә торган документлар

Тикшерүләрне үткәрүнең максатларына һәм бурычларына ирешер өчен күзәтү объектлары күрсәтә торган документлар, шулай да шул документларның формасын билгеләп куя торган норматив хокук актларның исемлеге 2 нче таблицада күрсәтелгән.

2 нче таблица. Тикшерүләрне үткәрүнең максатларына һәм бурычларына ирешер өчен күзәтү объектлары күрсәтә торган документлар исемлеге.

| Тикшерүне үткәрер өчен күрсәтелә торган документ | Документ формасын билгеләп куя торган норматив хокук акт |
|---|---|
| **Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә чараларны башкара торган җирле үзидарә органнары** | |
| Оешма җитәкчесе белән расланган һәм Татарстан Республикасы буенча Русия ГТХМ Баш идарәсе белән ризаланган табигый һәм техноген үзенчәлектәге гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча кушымталар белән гамәлләр планы. | - |
| Сугыш һәм тынычлык вакытында гадәттән тыш хәлләрне бетерер өчен муниципаль берәмлектә булган материаль чаралар запасын кору турында боерык.<br>Боерыкта билгеләнгән материаль чаралар саклауда булганны раслый торган бухгалтер документлары.<br>Сугыш һәм тынычлык вакытында гадәттән тыш хәлләрне бетерер өчен финанс резерв запасын кору турында боерык.<br>Счетларда билгеләнгән финанс чаралар булганын раслый торган документлар. | - |

| | |
|---|---|
| Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш саклау өлкәсендә финанс чараларны әмәлләрне башкаруга бүлеп бирүне раслый торган бухгалтер документлары (муниципаль берәмлек бюджетыннан яздырып алулар). | - |
| Муниципаль берәмлекнең билгеләп куелган тәртиптә эшкәртелгән, расланган һәм ризаланган иминлек паспорты. | “Русия Федерациясе субъектларының һәм муниципаль берәмлекләрнең типовой иминлек паспортын раслау турында” 2004 ел 25 нче октябрь № 484 РФ ГТХМ боерыгы |
| Җирле үзидарә органының вазифалы шәхесләре Татарстан Республикасы ГО һәм ЧС буенча УМЦ да һәм аның филиалларында законнар белән билгеләп куелган срокларда укыганны раслый торган документлар.<br>Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш саклау өлкәсендә җирле үзидарә органының эшчеләрен укытуы көнкүреш эштә җирле үзидарә органының хезмәткәрләрен укыту буенча узган ел нәтиҗәләре һәм алдагы елга укыту бурычлары турында түбәндәге кушымталар белән боерык нигезендә үткәрелә:<br>- елга өйрәнүләр һәм күнегүләр тематикасы;<br>- елга уку группаларының һәм дәрес җитәкчеләренең исемлеге;<br>- группалар буенча укыту программалары (җитәкче состав, штатта булмаган авария-коткару формированиеләре (алга таба – НАСФ), предприятие персоналы);<br>- Татарстан Республикасы ГО һәм ЧС буенча УМЦ да җитәкче һәм команда-башлыклар составын хәзерләү планы;<br>- персонал (җитәкче состав, НАСФ, предприятие персоналы) белән гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр буенча дәресләр расписаниесе.<br>Бу мәсьәләне тикшергән вакытта түбәндәгеләр булганы тикшерелә: | - |

| | |
|---|---|
| - дәресләрне үткәрү планнары, план-конспектлары;<br>- укучыларда үткәрелгән дәресләрнең конспектлары;<br>- дәресләрне алып бару исәбе журналы. | |
| Җирле үзидарә органы администрациясенең штатлы расписаниесендә халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген үзенчәлектәге гадәттән тыш хәлләрдән саклау буенча чаралар башкаруны оештыру һәм хәзерләү өчен җаваплы булган вазифалы шәхесе булу. | - |
| Гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә мәсьәләләрне хәл итәр өчен вәкаләт бирелгән җирле үзидарә органнарының структура бүлекчәләре (эшчеләре) турында кагыйдәнамә | - |
| Гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә мәсьәләләрне хәл итәр өчен вәкаләт бирелгән җирле үзидарә органнары эшчеләренең функциональ бурычлары. | |
| РФ законнарына туры килгән халыкны гадәттән тыш хәлләрдән саклау буенча өйрәнүләрне һәм күнегүләрне планлаштыруны һәм үткәрүне раслый торган документлар. | - |
| Халыкны гадәттән тыш хәлләр турында белдерү һәм хәбәр итеп тору системаларының коруын, дөрес карап торуын, техник карауын, эшли алганны тикшерүен раслый торган документлар булу.<br>Белдерү системасының техник үзенчәлекләре муниципаль берәмлек территориясендә яши торган халыкны вакытында белдерә алырга тиеш. | - |
Идарәара информацион үзара эш итү чикләрендә документларны яисә салым яисә закон белән башка сакланган сердән торган мәгълүматны сорау туры килгән мәгълүматларны тикшерү мәҗбүри таләпләрне үтәү фактын билгеләү кирәк булганга сәбәпле һәм билгеләнгән мәгълүматларны китерү федераль закон белән алдан исәпләнгән шартта ярый.

Идарәара информацион үзара эш итү чикләрендә документларны һәм (яисә) мәгълүматны тапшыру, аларны ачу, шул исәптән № 294-ФЗ Федераль законы белән алдан исәпләнгән очракларда алар белән танышу, дәүләт һәм закон белән башка сакланган сер турында Русия Федерациясе законнарының таләпләрен исәпкә алып башкарылалар.

Җирле үзидарә органы яисә җирле үзидарә вазифалы шәхесе белән мәгълүматны китерү турында Министрлыкның запросы җирле үзидарә органына яисә җирле үзидарә вазифалы шәхесенә аларның вәкаләте исәпкә алып җибәрелә. Турыдан-туры запросны карап тикшерү запроста булган сораулар компетенциясе белән бәйле булган җирле үзидарә органы җитәкчесе белән башкарыла.

Җирле үзидарә органнары яисә җирле үзидарә вазифалы шәхесләре белән күзәтү органының запросы буенча мәгълүматны китерер өчен күзәтү органы белән билгеләп куела торган срок 10 эш көненнән артык түгел.

Җирле үзидарә органы яисә җирле үзидарә вазифалы шәхесе белән мәгълүматны китерү срогын киметү гадәттән тыш хәлләргә, гражданнарның гомеренә һәм сәламәтлегенә янау, шулай да гражданнарның массакүләм хокукларын бозуга китерә торган Русия Федерациясе законнарын бозу фактларын билгеләгән очракларда ярый.

Җирле үзидарә органнары һәм җирле үзидарә вазифалы шәхесләре күзәтү органы белән соралган мәгълүматны китермәскә хаклы, әгәр бу мәгълүмат элек

китерелгән, я массакүләм мәгълүмат чараларында рәсми рәвештә матбугатка чыгарылган яисә “Интернет” информацион-телекоммуникацион системасында җирле үзидарә органының рәсми сайтында урнаштырылган булса. Шул ук вакытта җирле үзидарә органы, җирле үзидарә вазифалы шәхесе запроска җаваплаганда туры килгән мәгълүматның рәсми матбугатка чыгаруының яисә урнаштыруының чыганагын әйтә.

33. Күзәтү органында булган документларда булган мәгълүматлар һәм күзәтү объекты күрсәткән документларда булган мәгълүматлар нигезендә җаваплы башкаручы:

мәгълүматларның дөреслеген билгеләүне үткәрә;

күзәтү объекты эше билгеләп куелган мәҗбүри таләпләргә туры килгәнгә документларда булган мәгълүматларны тикшереп карый.

Документларда булган мәгълүматларның дөреслеге нигезле шик тудырган очракта, я бу мәгълүматлар күзәтү объекты мәҗбүри таләпләрне башкарганны сынарга мөмкинлек бирмәсә, күзәтү органына китерелгән һәм булган документларда хаталар һәм (яисә) каршылыклар, мәгълүматларның туры килмәүләре табылса, җаваплы башкаручы:

күзәтү объекты адресына мәгълүматларны сынау нәтиҗәләре турында мәгълүмат һәм дәлилләнгән запрос һәм ун эш көне эчендә язу формасында кирәкле аңлатмаларны, я карап тикшерү өчен башка документларны китерү таләбе белән хат (дәлилләнгән запрос) хәзерли;

кул куелганнан соң хатны (дәлилләнгән запросны) алу турында белдерү белән заказной почта, я алу турында билге белән җибәрелгән кеше аша җибәрә.

Башкару срогы: тикшерү башланыр алдыннан биш эш көне эчендә.

Гамәлнең нәтиҗәсе: күзәтү объекты адресына җибәрелгән документларны китерергә таләп итү белән хат (дәлилләнгән запрос).

34. Җаваплы башкаручы күзәтү объекты китергән документларны һәм (яисә) аңлатмаларны мәҗбүри рәвештә карап тикшерергә бурычлы. Китерелгән аңлатмаларны һәм (яисә) документларны карап тикшергәннән соң, я аңлатмалар булмаганда биредәге Административ регламентның III нче бүлегендә билгеләнгән мәҗбүри таләпләрне үтәмәү билгесе табылса, җаваплы башкаручы күчмә тикшерүне үткәрү турында министрның (министр урынбасарының) әмере проектын хәзерләп, күчмә тикшерүне башлап җибәрә.

Күчмә тикшерү (аны үткәрү турында карарны кабул иткәч) биредәге Административ регламентның 37 – 41 пунктларында китерелгән тәртипкә туры китереп башкарыла.

Күчмә тикшерүне үткәрү турында карарны министр (министр урынбасары) кабул итә.

Күзәтү объекты китергән аңлатмаларны һәм (яисә) документларны карап тикшергән вакытта мәҗбүри таләпләрнең табылган һәм күчмә тикшерүне үткәрер өчен нигез булып торган бозулары күчмә тикшерүне үткәрергә кирәк булганы турында карарны кабул итү критерие булып тора.

Башкару срогы: аңлатмаларны һәм (яисә) документларны алган вакыттан алып өч эш көне эчендә, әмма тикшерүне үткәрү датасыннан бирле 20 эш көненнән артыграк түгел.

Гамәлнең нәтиҗәсе: җаваплы шәхес белән карап тикшерелгән күзәтү объекты китергән аңлатмалары һәм (яисә) документлары; кирәк булганда күчмә тикшерүне үткәрү турында министрның (министр урынбасарының) әмере проекты.

35. Планлы документаль тикшерү нәтиҗәләре буенча җаваплы башкаручы ике нөсхәдә “Дәүләт контролен (күзәтүен) һәм муниципаль контролен тормышка ашырганда юридик шәхесләрнең һәм индивидуаль эшмәкәрләрнең хокукларын яклау турында” Федераль законының кагыйдәләрен реальләштерү турында” 2009 ел 30 нчы апрель № 141 Русия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгы боерыгы типовой формасы белән расланган күзәтү объектын күзәтү органы белән тикшерү актын төзи.

Тикшерү актында билгеләнәләр:

тикшерү актының датасы, вакыты һәм төзү урыны;

тикшерүне үткәргән күзәтү органының исеме;

тикшерүне үткәрү турында әмернең датасы һәм номеры;

тикшерүне үткәргән күзәтү органының вазифалы шәхесенең (шәхесләренең) фамилиясе, исеме, ата исеме һәм вазифасы;

тикшерелә торган күзәтү объектының булган урынының исеме һәм адресы, шулай да тикшерүне үткәргәндә булган җитәкченең, башка вазифалы шәхеснең яисә аның вәкаләтле вәкиленең фамилиясе, исеме, ата исеме һәм вазифасы;

тикшерүне үткәрүнең датасы, вакыты, озаклыгы һәм урыны;

тикшерүнең нәтиҗәләре турында мәгълүматлар, шул исәптән табылган билгеләп куелган халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген үзенчәлектәге гадәттән тыш хәлләрдән саклау таләпләре һәм чаралары бозылганы турында, аларның характеры турында һәм билгеләнгән бозуларны булдырган шәхесләр турында;

тикшерүне үткәргәндә булган күзәтү объектының җитәкчесе яисә вазифалы шәхесе тикшерү акты белән танышканы яисә танышудан баш тартуы, аларның имзалары булганы яисә кул куюдан баш тартулары турында мәгълүматлар, шулай да үткәрелгән тикшерү турында язуны тикшерүләр исәбе журналына кертү турында, я юридик шәхестә, индивидуаль эшмәкәрдә билгеләнгән журнал булмаган аркасында шундый язуны кертеп булмаганы турында мәгълүматлар;

тикшерүне үткәргән күзәтү органнарының вазифалы шәхесенең (шәхесләренең) имзасы (имзалары).

Тикшерү актын төзер өчен үткәрелгән тикшеренүләр, сынаулар, махсус расследованиеләр, экспертизаларның нәтиҗәләре буенча йомгакларны алырга кирәк булган очракта тикшерү акты контроль буенча чаралар тәмамланганнан соң өч эш көне срогыннан артык булмаган срокта төзелә, һәм күзәтү объектының җитәкчесенә, башка вазифалы шәхесенә яисә вәкаләтле вәкиленә кул куйдырып бирелә, я бирү турында белдерү белән заказной почта аша яисә бирелгәге актны төзегән шәхеснең сакланган квалификацион электрон имзасы куелган электрон документ формасында (тикшерелә торган шәхес дәүләт контроле (күзәтүе) яисә муниципаль контроль чикләрендә электрон формада үзара эш итүне башкарырга риза булган шартта) билгеләнгән документны алуны раслый ала торган юл белән җибәрелә.

Тикшерү актына үткәрелгән тикшеренүләр, сынаулар һәм экспертизаларның протоколлары яисә йомгаклары халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген үзенчәлектәге гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә табылган бозулар буенча күзәтү объектының вазифалы шәхесләренең аңлатмалары һәм тикшерү нәтиҗәләре белән бәйле булган башка документлар һәм аларның копияләре кушыла.

Тикшерү акты турыдан-туры тәмамланганнан соң ике нөсхәдә рәсмиләштерелә, аларның берсе кушымталар копияләре белән күзәтү объектының җитәкчесенә, башка вазифалы шәхесенә яисә вәкаләтле вәкиленә тикшерү акты белән танышу турында, я танышудан баш тарту турында кул куйдырып бирелә.

Юридик шәхеснең, индивидуаль эшмәкәрнең, аның вәкаләтле вәкиленең җитәкчесе, башка вазифалы шәхесе яисә вәкаләтле вәкиле булмаган очракта, шулай да тикшерелә торган шәхес тикшерү акты белән танышуга кул куюдан баш тарткан, я танышудан баш тарткан очракта тикшерү акты күзәтү органының делосында сакланган тикшерү акты нөсхәсенә теркәлгән бирү турында белдерү белән заказной почта аша җибәрелә. Тикшерелә торган шәхес электрон формада үзара эш итүгә риза булганда тикшерү акты бирелдәге актны төзегән шәхеснең сакланган квалификацион электрон имзасы куелган электрон документ формасында күзәтү объектының җитәкчесенә, башка вазифалы шәхесенә яисә вәкаләтле вәкиленә җибәрелергә мөмкин. Шул ук вакытта бирелдәге актны төзегән шәхеснең сакланган квалификацион электрон имзасы куелган электрон документ формасында тикшерелә торган шәхескә билгеләнгән документны алуны раслый торган юл белән җибәрелгән акт тикшерелә торган шәхес белән алган дип исәпләнә.

Планнан тыш күчмә тикшерүне үткәрер өчен аны үткәрүне прокуратура органы белән ризалау кирәк булган очракта тикшерү актының копиясе тикшерүне үткәрүне ризалау турында карар кабул иткән прокуратура органына тикшерү актын төзү көненнән бирле 5 эш көне эчендә җибәрелә.

Тикшерү нәтиҗәләре буенча халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген үзенчәлектәге гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә таләпләрне башкармау табылган очракта Русия Федерациясе законнары белән алдан исәпләнгән вәкаләт чикләрендә күзәтү органының вазифалы шәхесе бурычлы:

күзәтү объектына бозуларны бетерү буенча аларны бетерү срокларын билгеләп кушуны бирергә;

РФ Административ җинаятьләр кодексының 1 нче бүлеге 19.4 статьясы , 1 нче бүлеге 19.5 статьясы, 19.6 статьясы, 19.7 статьясы, 19.33 статьясы, 20.6 статьясы белән алдан исәпкә алынган административ җинаятьләр билгеләре табылганда закон белән билгеләп куелган тәртиптә тикшереп карала торган административ җинаятьләр турында эшләрне кузгата.

Халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген үзенчәлектәге гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә табылган бозуларны бетерү сроклары күзәтү органының вазифалы шәхесе белән бозуларны бетерүгә тәэсир итә торган бозуларның характеры, оештыру, техник, материаль факторлар исәпкә алып, билгеләп куела.

Бирелгән кушулар тикшерүләрне исәпләү журналында ул булганда исәпләнәләр. Кушуның копиясе күзәтү органында саклана.

Халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген үзенчәлектәге гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә административ җинаятьләр турында делолар административ җинаятьләр турында делоларны исәпләү журналында теркәлә.

Административ җинаятьләр турында делоларны исәпләү журналын мәгълүмат дубликатын магнит саклаучыда саклау һәм ел саен кәгазь саклаучыда ел саен архивлау шартта электрон рәвештә алып бару рөхсәт ителә. Журналны алып бару һәм тәмамланган журналны саклау срогы – 1 ел.

Юридик шәхеснең һәм индивидуаль эшмәкәрнең тикшерүләрне исәпләү журналы булмаганда тикшерүләр актында туры килгән язу башкарыла.

Тикшерү тәмамлангач 3 эш көне эчендә күзәтү органының вазифалы шәхесе тикшерүләрне исәпләү журналы булган очракта юридик шәхеснең һәм индивидуаль эшмәкәрнең тикшерүләрне исәпләү журналында үткәрелгән тикшерүне язып куя һәм югарыдагы җитәкчегә тикшерү нәтиҗәләрен белдерә.

Тикшерелгән күзәтү объектлары тикшерүләр актында язылган фактлар, йомгаклар, тәкъдимнәр белән, я табылган бозуларны бетерү турында бирелгән кушу белән риза булмаган очракта тикшерү актын алу датасыннан бирле унбиш көн эчендә тикшерү акты һәм (яисә) табылган бозуларны бетерү турында бирелгән кушу тарафына күзәтү органына язу формада тулысынча яисә аның аерым фикерләренә каршы килүләр китерергә хаклы. Шул ук вакытта күзәтү объекты шундый каршы килүләргә шундый каршы килүләрнең төпле булганын раслый торган документларны яисә аларның расланган копияләрен кушырга, я ризаланган срок эчендә аларны күзәтү органына тапшырырга хаклы. Билгеләнгән документлар тикшерелә торган шәхеснең сакланган квалификацион электрон имзасы куелган электрон документ формасында җибәрелергә мөмкин.

Башкару срогы:

тикшерү актын рәсмиләштерү һәм бирү: турыдан-туры тикшерүне тәмамлаганнан соң;

тикшерү актын заказной хат белән җибәрү: тикшерүне тәмамлаганнан соң бер эш көне эчендә.

Гамәлнең нәтиҗәсе: ике нөсхәдә төзелгән тикшерү акты, икесенең берсе күзәтү объектына бирелгән (җибәрелгән), икенчесе делога тегеп куелган.

36. “Күзәтү объектының планлы документаль тикшерүен үткәрү” административ процедурасын башкару нәтиҗәсе электрон формада күзәтү органының рәсми сайтына тикшерү тәмамланган көннән бирле 10 эш көненнән соңрак түгел беркетеп куела.

### “Күзәтү объектының планлы күчмә тикшерүен үткәрү” административ процедурасы

37. “Күзәтү объектының планлы күчмә тикшерүен үткәрү” административ процедурасын башлар өчен туры килгән күзәтү объектын күзәтү органының еллык Планына кертү, шулай да планлы документаль тикшерүне үткәрү

нәтиҗәсе булган планлы күчмә тикшерү турында әмер (биредәге Административ регламентның 34 нче пункты) нигез булып тора, димәк документаль тикшерү вакытында түбәндәгеләр мөмкин булмаса:

күзәтү органында сакланган күзәтү объектының документларында булган мәгълүматларның тулылыгын һәм дөреслеген тикшереп белергә;

контроль буенча туры килә торган чараны үткәрмичә, күзәтү объектының эшен мәҗбүри таләпләренә туры килүне сынарга.

Күчмә тикшерү (планлы да, планнан тыш та) күзәтү объектының булган урыны буенча һәм (яисә) үзенең фактик эш башкару урыны буенча үткәрелә.

Күзәтү объектының планлы күчмә тикшерүен планлы тикшерүләрнең еллык планына кертү биредәге Регламентның 23 нче пунктында билгеләнгән нигезләрдә башкарыла.

“Күзәтү объектының планлы күчмә тикшерүен үткәрү” административ процедурасы биредәге Административ регламентның 29 нчы пунктында билгеләнгән административ гамәлләр тәртибенә туры китереп башкарыла.

38. Җаваплы башкаручыны, экспертларны билгеләү, күзәтү объектын тикшерү турында әмерне хәзерләү, күзәтү объектын тикшерү турында белдерү биредәге Регламентның 30 – 32 пунктларында алдан исәпкә алынган тәртиптә башкарыла.

39. Җаваплы башкаручы, экспертлар, эксперт оешмаларның вәкилләре күзәтү объектына килгәннән соң тикшерүне түбәндәгеләрдән башлыйлар:

хезмәт таныклыкларын күрсәтү;

күзәтү объектының җитәкчесе яисә башка вазифалы шәхесе, аның вәкаләтле вәкиле күчмә тикшерүне билгеләү турында министрның (министр урынбасарының) әмере белән мәҗбүри танышуы;

күзәтү объектының җитәкчесе яисә башка вазифалы шәхесе, аның вәкаләтле вәкиле күчмә тикшерүне үткәрә торган шәхесләрне вәкаләте, шулай да күчмә тикшерүнең максатлары, бурычлары, нигезләре, контроль буенча чараларның төрләре һәм күләмнәре, күчмә тикшерүдә катнаштырыла торган экспертлар, эксперт оешмаларының вәкилләре составы, аны тикшерү сроклары һәм шартлары белән мәҗбүри танышуы.

Җаваплы башкаручылар, эксперт оешмаларының вәкилләре күзәтү объектының эше биредәге Административ регламентның III нче бүлегендә китерелгән мәҗбүри таләпләргә туры килүен сынап карый.

Башкару срогы: күзәтү объектының планлы күчмә тикшерүен үткәрүнең гомуми срогы – егерме эш көненнән артыграк түгел.

40. Региональ дәүләт күзәтүне тормышка ашыру буенча тикшерү актын төзү биредәге Административ регламентның 35 нче пунктында билгеләнгән тәртиптә башкарыла.

Җаваплы башкаручы юридик шәхесне һәм индивидуаль эшмәкәрне тикшерүләр исәбе журналында (булган очракта) үткәрелгән тикшерү турында күзәтү органы исеме, тикшерүне үткәрүнең башлану һәм тәмамлану даталары, аны үткәрү вакыты, хокук нигезләре, максатлары, бурычлары һәм тикшерү фәннәре, табылган бозулар һәм бирелгән кушулар турында мәгълүматлардан торган язу башкара, шулай да тикшерүне үткәрә торган вазифалы шәхеснең (шәхесләрнең) фамилияләре, исемнәре, ата исемнәре һәм вазифалары языла.

41. “Күзәтү объектының планлы күчмә тикшерүен үткәрү” административ процедурасын башкару нәтиҗәсе электрон формада күзәтү органының рәсми сайтына тикшерү тәмамланган көннән бирле 10 эш көненнән соңрак түгел беркетеп куела.

“Күзәтү объектының планнан тыш документаль тикшерүен үткәрү” административ процедурасы

42. “Күзәтү объектының планнан тыш документаль тикшерүен үткәрү” административ процедурасын башлар өчен биредәге Административ регламентның 24 нче пунктында билгеләнгән очраклар нигезләр булып тора.

“Күзәтү объектының планнан тыш документаль тикшерүен үткәрү” административ процедурасы түбәндәге гамәлләр тәртибенә туры китереп башкарыла:

тикшерүне үткәрү өчен җаваплы вазифалы шәхесләрне билгеләү турында карарны кабул итү;

тикшерүне үткәрү турында әмерне рәсмиләштерү;

тикшерүне үткәрү;

тикшерүнең нәтиҗәләрен рәсмиләштерү.

43. Министр (министр урынбасары) биредәге Административ регламентның 24 нче пунктында билгеләнгән планнан тыш тикшерүне үткәрер өчен нигезләр килеп чыккан вакытта күзәтү органының халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә региональ дәүләт күзәтү бүлегенең башлыгына планнан тыш документаль тикшерүне оештыру һәм үткәрү турында йөкләмә бирә.

Күзәтү органының халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә региональ дәүләт күзәтү бүлегенең башлыгы:

күзәтү объектының тикшерүен үткәрер өчен җаваплы башкаручысын билгели;

кирәк булган очракларда тикшерү үткәрелә торган күзәтү объекты белән граждан-хокук һәм хезмәт мөнәсәбәтләрендә булмаган һәм тикшерелә торган шәхесләрнең аффилирлы шәхесләре булмаган экспертларны, эксперт оешмаларын катнаштыра.

Башкару срогы: планнан тыш тикшерүне үткәрер өчен килеп чыккан нигезләр көненнән алып бер эш көне эчендә.

Гамәлнең нәтиҗәсе: күзәтү объектының планнан тыш тикшерүен башкарыр өчен билгеләнгән җаваплы башкаручы.

44. Күзәтү объектының планнан тыш тикшерүен үткәрү турында министр (министр урынбасары) әмерен хәзерләү биредәге Административ регламентның 31 нче пунктына туры китереп күзәтү объектының планнан тыш документаль тикшерүне үткәрер өчен җаваплы башкаручы билгеләнгән көндә башкарыла.

Гамәлнең нәтиҗәсе: министр (министр урынбасары) кулы куелган тикшерүне үткәрү турында әмер.

45. Күзәтү объектының документларында булган мәгълүматларны сынау, күзәтү объекты адресына хатны (дәлилләнгән запросны) хәзерләү, китерелгән документларда күзәтү объектының искәрмәләргә аңлатмаларын карап тикшерү

буенча җаваплы башкаручының гамәлләре биредәге Административ регламентның 33 – 34 пунктларына туры китереп башкарыла.

46. Тикшерү актын төзү, күзәтү объектының тикшерү акты белән (аларны рәсмиләштерү кирәк булганда кушымталар белән) танышу биредәге Регламентның 35 нче пунктында билгеләп куелган тәртиптә башкарыла.

Элек табылган законнарны бозулары бетерелгәне турында кушуны башкаруны тикшергәндә күзәтү органының законлы кушуын срокта башкармау, шулай да РФ Административ җинаятьләр кодексының ст. 19.5, 19.6 (туры килгәнчә) белән алдан исәпкә алынган административ җинаятьләрне булдыруга булыша торган сәбәпләрне һәм шартларны юк итү буенча чараларны кабул итмәү административ җинаятьләр турында эшне кузгатыр өчен нигез булып тора.

47. “Күзәтү объектының планнан тыш документаль тикшерүен үткәрү” административ процедурасын башкару нәтиҗәсе электрон формада күзәтү органының рәсми сайтына тикшерү тәмамланган көннән бирле 10 эш көненнән соңрак түгел беркетеп куела.

“Күзәтү объектының планнан тыш күчмә тикшерүен үткәрү” административ процедурасы

48. “Күзәтү объектының планнан тыш күчмә тикшерүен үткәрү” административ процедурасын башлар өчен биредәге Административ регламентның 24 нче пунктында билгеләп куелган очраклар нигез булып тора, шулай да документаль тикшерү вакытында түбәндәгеләр мөмкин булмаса:

күзәтү органында сакланган күзәтү объектының документларында булган мәгълүматларның тулылыгын һәм дөреслеген тикшереп белергә;

контроль буенча туры килә торган чараны үткәрмичә, күзәтү объектының эшен мәҗбүри таләпләренә туры килүне сынарга.

49. Күзәтү объектының планнан тыш күчмә тикшерүен үткәрер өчен җаваплы башкаручыны билгеләү, экспертларны катнаштыру биредәге Административ регламентның 30 нчы пунктына туры китереп башкарыла.

50. Күзәтү объектының планнан тыш күчмә тикшерүен үткәрү турында министр (министр урынбасары) әмерен хәзерләү биредәге Административ регламентның 31 нче пунктына туры китереп башкарыла.

51. Биредәге Административ регламентның 24 пункты “а”, “б” пункт асларында билгеләнгән нигезләр планнан тыш күчмә тикшерүне үткәрер өчен нигезләр булган очракта җаваплы башкаручы:

күзәтү объектының планнан тыш күчмә тикшерүен үткәрүне ризалау турында күзәтү объекты эшен башкару урыны буенча прокуратура органына гариза хәзерли һәм аны министрда (министр урынбасарында) имзалый;

күзәтү объектының планнан тыш күчмә тикшерүен үткәрүне ризалау турында күзәтү объекты эшен башкару урыны буенча прокуратура органына җибәрелгән кеше аша, бирү турында белдерү белән заказной почта аша яисә сакланган квалификацион электрон имза куелган электрон документ формасында гаризаны җибәрә.

Гаризага планнан тыш күчмә тикшерү турында министр (министр урынбасары) әмере копиясе һәм аны үткәрер өчен нигез булган мәгълүматлардан торган документлар кушыла.

Башкару срогы: күзәтү объектының планнан тыш күчмә тикшерүен үткәрү турында министр (министр урынбасары) әмеренә кул куелган көндә.

Гамәлнең нәтиҗәсе: планнан тыш күчмә тикшерүне ризалау турында прокуратура органына җибәрелгән гариза.

Кешеләрнең гомеренә, сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирә мохиткә, Русия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарих һәм мәдәният памятникларына), дәүләт иминлегенә зыян китерү, шулай да табигый һәм техноген үзенчәлекле гадәттән тыш хәлләр килеп чыгу, мәҗбүри таләпләрнең бозулары табылу планнан тыш күчмә тикшерү өчен нигез булып торсалар, шундый бозуларны булдыру вакытында кичектергесез чараларны кабул итү кирәклеге аркасында күзәтү органы планнан тыш күчмә тикшерүне үткәрү турында гаризаны, планнан тыш күчмә тикшерүне үткәрү турында әмер копиясен һәм аны үткәрер өчен нигез булган мәгълүматлардан торган документларны егерме дүрт сәгать эчендә прокуратура органнарына җибәреп прокуратура органнарын белдереп планнан тыш күчмә тикшерүне үткәрергә башларга хаклы. Бу очракта прокурор яисә аның урынбасары планнан тыш күчмә тикшерүне үткәрүне ризалау турында карарны туры килгән документлар килү көнендә кабул итә.

52. Җаваплы башкаручы күзәтү объектын планнан тыш күчмә тикшерүне үткәрү турында (планнан тыш күчмә тикшерүдән тыш, аның үткәрү нигезләре биредәге Административ регламентның 24 нче пунктының өченче абзацында билгеләнгән) аны үткәрер алдыннан егерме дүрт сәгатьтән ким түгел нинди дә булса мөмкин юл белән белдерә.

Күзәтү объекты эше нәтиҗәсе буларак, кешеләрнең гомеренә, сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирә мохиткә, Русия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарих һәм мәдәният памятникларына), дәүләт иминлегенә зыян китерелгән яисә китерелә торган очракта, шулай да табигый һәм техноген үзенчәлекле гадәттән тыш хәлләр килеп чыкса яисә килеп чыга алса, күзәтү объектын планнан тыш күчмә тикшерүне үткәрү турында алдан белдерү таләп ителми.

53. Планнан тыш күчмә тикшерүне үткәрү биредәге Административ регламентның 39 нчы пунктына туры китереп башкарыла.

Элек табылган законнарны бозулары бетерелгәне турында кушуны башкаруны тикшергәндә күзәтү органының законлы кушуын срокта башкармау, шулай да РФ Административ җинаятьләр кодексының ст. 19.5, 19.6 (туры килгәнчә) белән алдан исәпкә алынган административ җинаятьләрне булдыруга булыша торган сәбәпләрне һәм шартларны юк итү буенча чараларны кабул итмәү административ җинаятьләр турында эшне кузгатыр өчен нигез булып тора.

54. Региональ дәүләт күзәтүне башкару буенча актны төзү биредәге Административ регламентның 40 нчы пунктына туры китереп башкарыла.

Планнан тыш күчмә тикшерү прокуратура органы белән ризалау буенча башкарылса, региональ дәүләт күзәтүне башкару буенча акт копиясе

прокуратура органына региональ дәүләт күзәтүне башкару буенча тикшерү акты төзелгән көненнән алып биш көн эчендә җибәрелә.

55. Үзен көйли торган оешма членнары мәҗбүри таләпләрне бозу фактлары табылган очракта җаваплы башкаручы үзен көйли торган оешмага табылган бозулар турында планнан тыш күчмә тикшерүне үткәрү тәмамланган көннән алып биш эш көне эчендә хәбәр итә.

Табылган мәҗбүри таләпләрнең бозуын күзәтү объекты белән юк итү турында кушуны башкару срогы чыгу планнан тыш күчмә тикшерүне үткәрер өчен нигез булып торган очракта шундый тикшерүнең фәне күзәтү органы биргән кушуны башкару гына булып тора ала.

56. “Күзәтү объектының планнан тыш күчмә тикшерүен үткәрү” административ процедурасын башкару нәтиҗәсе электрон формада күзәтү органының рәсми сайтына тикшерү тәмамланган көннән бирле 10 эш көненнән соңрак түгел беркетеп куела.

## VI. Дәүләт функциясен башкару артыннан контроль тәртибе һәм формалары

57. Күзәтү органы вазифалы шәхесләр хезмәт бурычларын башкару артыннан контрольне башкара, тикшерүләрне үткәргәндә вазифалы шәхесләр вәкаләтен тиешенчә башкармау очраклар исәбен алып бара, туры килә торган хезмәт тикшеренүләрен үткәрә һәм Русия Федерациясе законнарына туры китереп шундый вазифалы шәхесләр тарафына чаралар кабул итә.

58. Биредәге Административ регламентны башкару артыннан контроль министр белән башкарыла.

59. Биредәге Административ регламентка туры китереп региональ дәүләт күзәтүне башкару буенча срокларны, гамәлләр эзлеклелелеген үтәү артыннан, күзәтү органының вазифалы шәхесләре карарларны кабул итү артыннан агымдагы контрольне күзәтү органының министр урынбасары һәм вәкаләтле шәхесләре башкара.

60. Дәүләт күзәтү функциясенең агымдагы контролен башкарырга вәкаләт бирелгән күзәтү органының эшчеләре исемлеге, шул контрольне башкару тәртибе һәм кабатланып торуы күзәтү органы актлары белән билгеләп куела. Күзәтү органы эшчеләренең агымдагы контрольне башкаруга бирелгән вәкаләте күзәтү органының структура бүлекчәләре турында кагыйдәнамәләрдә, эшчеләрнең вазифалы инструкцияләрендә билгеләнә.

61. Күзәтү органы белән дәүләт функциясен тулы һәм сыйфатлы башкару артыннан контроль планлы һәм планнан тыш тикшерүләр үткәрүдән, тикшерелә торган шәхесләрнең хокукларын бозуларын эзләп табу һәм юк итүдән, күзәтү органының вазифалы шәхесләренең гамәлләренә (бер нәрсә дә эшләмәүгә) шикаятьләрдән торган кызыксынган шәхесләрнең мөрәҗәгатьләре буенча карап тикшерүләрдән, карарларны кабул итүдән һәм җавапларны хәзерләүдән тора.

Тикшерүләр министр (министр урынбасары) әмеренең нигезендә үткәреләләр. Тикшерүләрнең нәтиҗәләре дәүләт функциясен башкарганда

кимчелекләр булмаганы, я табылган кимчелекләр һәм аларны бетерү буенча тәкъдимнәр язылган акт төрендә рәсмиләштерелә.

62. Дәүләт функциясен тулы һәм сыйфатлы башкаруның планлы тикшерүләре ТР Экология һәм табигый байлыклар министрлыгының агымдагы елга еллык эш планына туры китереп үткәрелә. Планлы тикшерүләр билгеләнгән планга дәүләт функциясен башкара торган министр урынбасары белән кертелә.

63. Дәүләт функциясен тулы һәм сыйфатлы башкаруның планнан тыш тикшерүләре дәүләт функциясен башкарган вакытта кабул ителгән яисә башкарылган күзәтү органының вазифалы шәхесләренең карарларына яисә гамәлләренә (бер нәрсә дә эшләмәүгә) шикаятьләр нигезендә үткәрелә.

64. Үткәрелгән тикшерүләр нәтиҗәләре буенча дәүләт функциясен башкарган вакытта күзәтү органының вазифалы шәхесләре булдырган бозулар табылган очракта гаепле шәхесләр Русия Федерациясе законнарына туры китереп җавапка тарттырыла һәм табылган бозуларны бетерү буенча чаралар кабул ителә.

## VII. Күзәтү органының, шулай да аның вазифалы шәхесләренең карарларына һәм гамәлләренә (бер нәрсә дә эшләмәүгә) риза булмыйча судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү тәртибе

65. Күзәтү объектының җитәкчесе, башка вазифалы шәхесе яисә вәкаләтле вәкиле, башка кызыксынган шәхесләр (алга таба – гариза бирүчеләр) күзәтү органының, аның вазифалы шәхесләренең дәүләт функциясен башкарган вакытта кабул ителгән (башкарыла торган) гамәлләренә (бер нәрсә дә эшләмәүгә) һәм карарларына Русия Федерациясе законнарына туры килгән тәртиптә риза булмыйча судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирергә хаклы.

66. Шикаять түбәндәгеләрдән торырга тиеш:

- карарларына һәм гамәлләренә риза булмыйча шикаять бирелә торган күзәтү органының исеме, я вазифалы шәхеснең фамилиясе, исеме, ата исеме;
- гариза бирүченең фамилиясе, исеме, ата исеме (соңгысы – булганда) тору урыны турында мәгълүматлар, шикаять бирә торган юридик шәхеснең исеме, электрон почта адресы, әгәр җавап электрон документ формасында җибәрелергә тиеш булса, һәм почта адресы, әгәр җавап язу формасында җибәрелергә тиеш булса;
- шикаять бирелә торган күзәтү органының һәм вазифалы шәхеснең карарлары һәм гамәлләре (бер нәрсә дә эшләмәү) турында мәгълүматлар;
- гариза бирүче күзәтү органының һәм вазифалы шәхеснең карарлары һәм гамәлләре (бер нәрсә дә эшләмәү) белән риза булмыйча дәлилләр. Гариза бирүче дәлилләрен раслый торган документларны (булганда), я аларның копияләрен китерә ала.

67. Күзәтү органының, аның вазифалы шәхесләренең гамәлләренә (бер нәрсә дә эшләмәүгә) риза булмыйча судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирүнең фәне дәүләт функциясен башкарган вакытта кабул ителгән яисә башкарылган күзәтү органының вазифалы шәхесләренең карарлары яисә гамәлләре (бер нәрсә дә эшләмәү) булып тора.

68. Күзәтү органына яисә вазифалы шәхескә аларның компетенциясенә буенча килгән шикаять мәҗбүри рәвештә карап тикшерелергә тиеш. судка кадәр (судтан тыш) шикаятьне карап тикшерүне кире кагу яисә карап тикшерүне туктатып тору өчен нигезләр алдан исәпкә алынмаган.

69. Язу шикаятьтә шикаятьне җибәргән гражданинның фамилиясе (юридик шәхеснең исеме) яисә җавап җибәрелергә тиеш булган почта адресы (электрон почта адресы) билгеләнмәгән очракта шикаятькә җавап бирелми. Әгәр билгеләнгән шикаятьтә хәзерләнә торган, башкарыла торган яисә хокукка каршы башкарылган эш турында, шулай да аны хәзерли торган, башкара торган яисә башкарган шәхес турында мәгълүматлар булса, шикаять туры килгән компетенцияле дәүләт органына җибәрелергә тиеш.

Язу шикаятьнең текстын укып булмаслык очракта шикаятькә җавап бирелми, моның турында  шикаятьне теркәү көненнән бирле җиде көн эчендә шикаятьне җибәргән гариза бирүчегә, әгәр аның фамилиясе (юридик шәхеснең исеме) һәм почта адресын укып булса, хәбәр ителә.

Гариза бирүченең шикаятендә элек җибәрелгән шикаятьләр аркасында мәсьәлә буенча кат-кат язу җаваплар бирелгән сорау булган очракта һәм шул ук вакытта шикаятьтә яңа дәлилләр һәм шартлар китерелмәгән очракта министр билгеләнгән шикаять һәм элек җибәрелгән шикаятьләр бер үк күзәтү органына, җирле үзидарә органына яисә вазифалы шәхескә җибәрелгән шартта биредәге сорау буенча чираттагы шикаять нигезсез булу һәм гариза бирүче белән язышуны туктату турында карарны кабул итәргә хаклы.

Шикаятьтә куелган сорауның мәсьәләсе буенча җавап дәүләт яисә федераль закон белән саклана торган башка сердән торган мәгълүматларны ачып салмыйча бирелә алмый торган очракта шикаятьне җибәргән гариза бирүчегә билгеләнгән мәгълүматларны ачып салу ярамау аркасында анда куелган сорауның мәсьәләсенә җавап бирү мөмкин булмаган очракта.

Әдәпсез, я мыскыллы әйтемнәрдән торган, вазифалы шәхесенең, шулай да аның гаилә членнарының гомеренә, сәламәтлегенә һәм милегенә янаулардан торган  язу шикаятьне алганда күзәтү органы шикаятьтә куелган сорауларга җавап бирмичә калдырырга һәм шикаятьне җибәргән гариза бирүчегә хокукны кирәгеннән артык куллану ярамаганы турында хәбәр итәргә хаклы.

Суд карары белән риза булмаган шикаять теркәү көненнән алып җиде көн эчендә биредәге суд карарына риза булмау тәртибен аңлату белән шикаятьне җибәргән гариза бирүчегә кире кайтарыла.

Әгәр шикаятьтә куелган сорауларга җаваплар бирелергә мөмкин булмаган сәбәпләр киләчәктә бетерелгән булса, гариза бирүче шикаятьне күзәтү органына тагын җибәрергә хаклы.

70. Күзәтү органының, аның вазифалы шәхесләренең гамәлләренә (бер нәрсә дә эшләмәүгә) риза булмыйча судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү процедурасын башлар өчен гариза бирүченең үзеннән яисә почта җибәрү, Интернет челтәрен, шул исәптән күзәтү органының рәсми сайтын, Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль уңайлыклар порталын кулланып электрон документ төрендә күзәтү органына шикаять килү нигез булып тора.

71. Күзәтү объектлары шикаятьне нигезләр һәм карап тикшерер өчен кирәкле мәгълүматны һәм документларны алырга хаклы. Шундый төрдәге

мәгълүматны һәм документларны алыр өчен күзәтү объектлары күзәтү органы адресына язу яисә электрон формада туры килә торган запрос җибәрергә тиеш. Министр (министр урынбасары), җаваплы башкаручылар запросны теркәү көненнән алып 30 көн эчендә соралган мәгълүматларны һәм документларны бирергә бурычлы.

72. Күзәтү органының вазифалы шәхесләренең гамәлләренә (бер нәрсә дә эшләмәүгә) шикаять министрга җибәрелергә мөмкин. Күзәтү органының һәм министрның гамәлләренә (бер нәрсә дә эшләмәүгә), карарларына шикаять Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына җибәрелергә мөмкин.

73. Күзәтү органына килгән шикаять аның теркәү көненнән алып 30 календарь көне эчендә карап тикшерелә.

74. Судка кадәр (судтан тыш) шикаять нәтиҗәләре түбәндәгеләр булып тора:

дәүләт функциясен башкарган вакытта кабул ителгән (башкарылган) гамәлләргә (бер нәрсә дә эшләмәүгә) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирүне канәгатьләндерү;

региональ дәүләт функциясен башкарган вакытта кабул ителгән (башкарыла торган) гамәлләргә (бер нәрсә дә эшләмәүгә) һәм карарларга судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирүне канәгатьләндермичә калдыру.

Шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре турында дәлилләнгән җавап гариза бирүчегә язу формасында һәм гариза бирүченең теләге буенча электрон формада биредәге Административ регламентның 73 нче пунктында билгеләнгән срок эчендә җибәрелә.

Административ регламентка
Кушымта № 1

Дәүләт функциясен башкаруның блок-схемасы




Тәмамлану көнендә тикшерү актын ике нөсхәдә төзү
Административ җинаять турында эш кузгату
Табылган бозуларны бетерү турында кушуны төзү һәм бирү
Компетенциягә туры килгән дәүләт хакимияте органнарына мәгълүматны җибәрү
РФ Административ җинаятьләр кодексына туры килгәнчә административ җитештерү
Халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген үзенчәлектәге гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә законнарны бозуны бетерү артыннан күзәтү
Акт (табылган бозуларны бетерү турында кушу) белән танышу һәм аны күзәтү объектына бирү – турыдан-туры тикшерүне тәмамлаганнан соң
Күзәтү объектына кушымталар копияләре белән тикшерү актын бирү яисә бирү турында белдерү белән почта элемтәсе аша җибәрү – тикшерүне тәмамлаганнан соң бер эш көне эчендә
Прокуратура органына тикшерү акты копиясен җибәрү (прокуратура органы белән ризалау булганда) – актны төзегән көннән бирле биш эш көне эчендә
Күчмә тикшерүне үткәрү турында исәп журналында җаваплы башкаручының язмасы – тикшерү тәмамланганнан соң өч эш көне эчендә
Тикшерү нәтиҗәсен рәсми сайтта урнаштыру – тикшерү тәмамланганнан соң ун эш көненнән соңрак түгел